*Туган телем - иркә гөлем, киңдер сиңа күңел түрем...*

# КҮМӘК КӨЧ

ГОМУМИ РАЙОН ТАТАР ГАЗЕТАСЫ
1930 елдан чыга.
Бәясе ирекле
№ 22 (10714)
Чәршәмбе,
31 май 2017 ел.
(Атнага бер тапкыр чыга)

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫЛАР: 1. УЛЬЯНОВСК ӨЛКӘСЕ ХӨКҮМӘТЕ (432017, Ульяновск шәһәре, Ленин мәйданы, 1). 2. "ИСКЕ КУЛАТКЫ РАЙОНЫ" МУНИЦИПАЛЬ БЕРЛӘШМӘСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ (433940, УЛЬЯНОВСК ӨЛКӘСЕ, ИСКЕ КУЛАТКЫ ЭШЧЕЛӘР БИСТӘСЕ, ПИОНЕРСКАЯ УРАМЫ, 30)

## Соңгы кыңгырау, соңгы чыңлау

**Ниһаять, тагы бер уку елы уңышлы гына үтеп китте. 24-25 май көннәрендә илебезнең барлык мәктәпләрендә мөңләгән чыгарылыш класс укучылары өчен соңгы кыңгырау яңгырады. Соңгы кыңгырау, соңгы чыңлау, кабатланмас хатирәләр, дулкынландыргыч мизгелләр булып һәркемнең күңел түрендә саклана ул. Быел мәктәп белән саубуллашып, район буенча IX сыйныфны - 85, XI сыйныфны – 43 укучы тәмамлады.**

**(Дәвамы 3 биттә).**





## Сәнгать мәктәбе сайрар кошларын очырды

Район балалар сәнгать мәктәбендә дә шау-гөр килеп чыгарылыш сыйныф укучылары белән саубуллаштылар. Әлеге уку йортында белем һәм тәрбия алучы укучыларның саны да елдан-ел артып тора, белем учагы яшь кадрлар белән тулылана, биредә белем алу өчен барлык шартлар да тудырылган. Мәктәп директоры Ләйлә Рушан кызы Амирова энергиясе ташып торган җитәкче, бар җиргә дә өлгерә. Балаларга белем бирү белән бергә мәктәптә уңай шартлар булдыруга да күп тырышлык куйган. “Бердәм Россия” партиясенең урындагы башкарма комитеты җитәкчесе булуы да моңа ярдәм иткәндер, бәлки. Чөнки балаларны, сәнгатьне яратучы, “Бердәм Россия” партиясенең политсовет Секретаре Э.Ә. Ганеев мәктәпкә гел ярдәм итеп тора. Шуңа күрә бирегә килеп керергә сокланыч, балаларга уңай һәм күңелле. Быелгы уку елында балалар сәнгать мәктәбенең чыгарылыш төркеме: хезмәт сөючән Элина Яфарова, иң актив Диана Тимушева, шат күңелле Солтан Мәгдиев, иң гүзәл Эльвина Сөләйманова, иң эрудицияле Динара Арсланова, иң ягымлы Юлия Аббәсова, иң дипломатияле Илдар Яхин, бигрәк позитив Айсылу Мәгдиева, иң күркәм Эльвира Деникаева, хыялланырга яратучы Элина Рахманкуллова, тормышны сөюче Солтан Хабиев, иң тырыш Элина Мостафина, иң дәртләндерүче Эльвина Усманова , иң романтик Люция Аблязова, төрле яктан җитешкән Альбина Валиева уңышлы тәмамладылар. Бәйрәмдә һәр укучы үзенең мәктәптә алган сәләтен күрсәтеп калырга ашыкты. Алар баян һәм фортепианода уйнадылар, күңелле җырлар яңгыраттылар. Район администрациясе Башлыгының кеше потенциалын үстерү буенча урынбасары, сәнгать мәктәбе укытучысы да әле В. А. Деникаева укучыларга кызыл таныклыклар тапшырып, уңышлар теләде, алган белемнәренең тормышта кирәкле булуын әйтеп, актив укучыларга Почет грамоталары тапшырды. Быел, беренчеләрдән булып, рәсем сәнгате буенча да бер укучы сәнгать мәктәбен тәмамлады. Аның рәсемнәреннән күргәзмә ясалган иде .



\- Без яшь сәнгатькәрләребез белән дә горурланабыз, аларга тормышта үз урыннарын табарга ярдәм дә итәчәкбез. Белгечлек алып үз мәктәбебезгә үк укытырга кайтсалар да, шатланачакбыз гына, - дип сүзен тәмамлады В.А. Деникаева.

"Без, чыгарылыш сыйныф укучыларының әти-әниләре, балалар сәнгать мәктәбе укытучыларына зур, олы рәхмәтләребезне җиткерәбез, иҗади уңышлар теләп калабыз. Күңел җылыгыз саекмасын, уку йортыгыз сәләтле балалар белән тулып торсын", - дигән фикерләр дә яңгырады, без дә әлеге сүзләргә бик теләп кушылабыз.

**Майзә МАСИЕВА.**

### “Таң йолдызы”-на килегез!

**1 июнь – Халыкара балаларны яклау көне уңаеннан район мәдәният йортында традицион “Таң йолдызы” балалар җыры фестивале үтә. Җыр конкурсы пәнҗешәмбе көнне 10.00 сәгатьтә башлана. Бәйрәм программасында: җыр – моңга, биюгә сәләтле балаларның чыгышлары, иҗади эшләренең күргәзмәсе һәм яшь талантларны бүләкләү тантанасы булачак.**

### Чәчү-2017

## Мул уңышка ышаныч бар

Май аеның яуган яңгырлары авыл хуҗалыгындагы чәчү эшләрен бераз тоткарлады. Ләкин явым-төшемнең күп булуы бер дә комачауламый, киресенчә, киләсе уңышка нык нигез генә сала.

Безнең Иске Кулаткы районында быел план буенча 23069 гектарда сабан культуралары чәчү планлаштырылган иде. 28 май көненә күрсәтелгән мәйданнарның 20796 гектары чәчелде яисә бу башкарылган эшнең 90 проценты дигәнне аңлата. Хуҗалыкларның күпчелеге бөртекле культураларны чәчүне төгәлләделәр дияргә була. Бүгенге көнгә бөртекле культураларның шытып чыгуы уңай дәрәҗәдә.

Язгы кыр эшләрен төгәлләгән хуҗалыклар шытып чыккан техник культураларны эшкәртү өчен техникаларын җайлауга керештеләр. Шул ук вакытта бөҗәкләргә каршы көрәш алып бару өчен агулы химикатлар табыштыру да башкарыла.

Авыл хуҗалыгы белгечләренең прогнозлавы буенча быел кырлардан мул уңыш алуы көтелә.

**Р. АРИФУЛЛИН.**

## 1 июнь – Халыкара балаларны яклау көне

### Кадерле балалар, хөрмәтле әти-әниләр!

Һәр елның җәй башында бөтен Җир шары иң матур һәм иң якты бәйрәмнәрнең берсе булган Халыкара балаларны яклау көнен билгеләп үтә. Яшәешнең төп мәгънәсе – балалар. Аларның елмаюы һәм бәхетле карашлары – җир йөзендәге иң зур байлыктыр, мөгаен. Ә бәйрәм – Балаларны яклау көне исә һәр баланың да бәхетле һәм күңелле балачагы булырга тиешлекне аңлата. Балаларның киләчәген бәхетле итү – ул безнең бурыч. Сезгә һәм әти-әниләрегезгә бәхет һәм сәламәтлек телим, һәрчак аларның игътибарын, мәхәббәтен һәм күңел җылылыгын тоеп яшәгез. Йөзегездән елмаю китмәсен, күңелегездә якты хисләр генә ташып торсын. Әти-әниләрегез сезнең белән һәрвакыт горурлансыннар иде.

Халыкара балаларны яклау көне сөенечле мизгелләр – көтеп алган каникуллар башлану чоры белән туры килә. Җәй айларын истә калырлык һәм кызыклы итеп үткәрегез.

Кадерле балалар, сәламәт, акыллы, белемле һәм игелекле булып үсегез! Сез – безнең киләчәгебез, безнең өметебез!

**Э.Ә. ГАНЕЕВ,**
**Иске Кулаткы районы Башлыгы, “Бердәм Россия” партиясенең урындагы политсовет Секретаре.**
**И.А. АБЛЯЗОВ,**
**Иске Кулаткы район администрациясе Башлыгы.**

| ПӘНҖЕШӘМБЕ (01.06.) | ҖОМГА (02.06.) | ШИМБӘ (03.06.) | ЯКШӘМБЕ (04.06.) | ДҮШӘМБЕ (05.06.) | СИШӘМБЕ (06.06.) | ЧӘРШӘМБЕ (07.06.) |
|---|---|---|---|---|---|---|
| + 24 | + 19 | + 13 | + 12 | + 14 | + 18 | + 20 |
| + 12 | + 8 | + 4 | + 4 | + 6 | + 9 | + 11 |

## ЯҢАЛЫКЛАР



Мәскәүдә көчле давыл нәтиҗәсендә 11 гә якын кеше һәлак булган, дистәгә якын кеше зыян күргән. Ил Башлыгы В.В. Путин Мәскәүдәге гарасатта үлүчеләрнең якыннарының кайгыларын уртаклашты. Һәлак булучыларның гаиләләренә 1 миллион сум акча бүлеп биреләчәк.

● ● ●

Россия Президенты Владимир Путин Россиядә 2018-2027 елларны Балачак унъеллыгы буларак игълан итү турындагы указны имзалаган. Документ тексты хокук порталында урын алган. “Россия Федерациясендә 2018 – 2027 елларны Балачак унъеллыгы дип игълан итәргә”, – диелгән указда.

● ● ●

Россия Президенты Владимир Путин 2012 елгы май карарына эләкмәүче бюджет хезмәткәрләренең эш хакын арттырырга тәкъдим итте. Ул бу хакта РФ Хөкүмәте әгъзалары катнашындагы утырыш барышында әйткән. Ил башлыгы шул ук вакытта карарга кермәгән категориядәге бюджетникларның хезмәт хакын арттырганда, инфляцияне һәм федераль, төбәк бюджетларының мөмкинлеген исәпкә алырга кушты.

● ● ●

Россия Президенты Владимир Путин хәрбиләрне, гражданлык хезмәткәрләрен һәм Россия Федераль куркынычсызлык хезмәтенең чик буенда эшләгән ветераннарын Чик сакчылары көне белән котлады. “Бүген без Россиянең чикләрен ышанычлы итеп яклаучыларны, туган җиребезне дошманнан саклаучыларны олылыйбыз ", – дип әйтелә дәүләт Башлыгының котлавында.



Регион Башлыгы Сергей Морозов П. А. Столыпин исемендәге Ульяновск дәүләт аграр университетының чыгарылыш сыйныф укучыларына бер миллион сум күләмендә түләү бирү турындагы инициатива белән чыкты. Әлеге акчалата түләүне алуга "Ветеринария", "Агрономия" һәм "Зоотехния" юнәлешләре буенча авыл җиренә эшкә урнашкан яшь белгечләр өмет итә ала.

● ● ●

Губернатор Сергей Морозовның боерыгы буенча өлкәбездә сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау буенча системалы эш алып барыла. Халыкара балаларны яклау көнендә Ульяновск өлкәсенең барлык дәвалау учреждениеләрендә профилактик акцияләр узачак. 1 июньдә поликлиникаларда 220 дән артык мәгълүмати -агарту чаралары үткәрү планлаштырыла.

● ● ●

Ульяновск өлкәсендә янгын куркынычы классы кимеде. Уңай динамикага урманчылыклар, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү Үзәгенең уртак гамәлләре һәм табигать шартлары нәтиҗәсендә ирешеп булды. Исегезгә төшерәбез, элегрәк Губернатор Сергей Морозов янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү һәм кисәтүгә юнәлдерелгән чараларны көчәйтергә чакырган иде

**5 июнь - Бөтендөнья тирә-мөхитне саклау көне**

# Башкалар да җавапсыз калмасын

Шушы көннәрдә “Кумәк көч” район газетасының журналистлары район экологы Х. Җ. Аминов белән Иске Кулатка эшчеләр поселогы урманнарының чисталыгын тикшерү буенча рейд ясадылар.

Читтән карап торганда район үзәгендә урнашкан урманнар сокланырлык матур итеп чистартылган. Ләкин тыкрыкларга, арт урманнарга керсәң, алай ук түгел икән. Мәсәлән, Иске Кулаткы район балаларга өстәмә белем бирү үзәге бинасыннан ерак түгел искиткеч гаҗәп, аяныч күренеш ята. Бирадә пла-



стик шешәләр, таушалган целлофан пакетлары, чүп-чар кәгазьләре ерактан ук ямьсез күренеш тудыралар.

- Бу территория Иске Кулаткы район балаларга өстәмә белем бирү үзәгенә беркетелгән һәм аның өчен әлеге оешма җавап бирергә тиеш, - дип әйтә район экологы Х. Җ. Аминов.

Балаларга өстәмә белем бирү үзәге директоры Р. Н. Кузеев: “ Бу чүп-чар безнең территориягә кагылмый һәм аның чынбарлыгын район архитектура документлары раслый. Закон нигезендә безнең оешма районның “Төзекләндерү” оешмасы белән чүп-чарны алу буенча килешүләр төзеде һәм без аның таләпләрен үтибез.

Безнең оешмадан башка бирегә чүп-чарны якын тирәдәге кибетләр дә,- шунда яшәүче гаиләләр дә ташлый. Район Советы депутаты буларак мин район экологыннан әлеге мәсьәләне контрольдә тотуын соралыр идем. Бирәдә яшәүче гаиләләр, индивидуаль эшмәкәрләр дә районның “Төзекләндерү” оешмасы белән килешүләр төзесеннәр иде. Шул очракта гына тулаем тәртип урнашыр".

Дөрестән дә шулай икән. Кибетләр сату белән генә шөгыльләнмәсеннәр, үзләре ташлаган чүп-чарны да җыештырсыннар иде.

**Рөстәм АРИФУЛЛИН.**

## Яшьләр парламенты да тулы хокуклы



Үткән атнада район Советы депутатларының тугызынчы чираттагы утырышы булды. Аны район Башлыгы, район Советы депутатлары рәисе Э.Ә. Ганеев алып барды. Утырышта хәзер район яшьләре парламенты да катнаша. Алар барлык депутатлар кебек үк мәсьәләләрне чишүдә, тавыш бирүдә тулы хокукка ия булып торалар. Әлеге яңа башлангыч яшьләребезгә районның социаль - экономик хәлен аңларга, район бюджетын тулыландыру чаралары турында күзаллый алалар. Көн тәртибенә алты мәсьәлә куелган иде. Әлеге утырышның кайсыбер карарларын газета укучылар карамагына да тәкъдим итәлә. **(Алар 5 биттә).**

## СООБЩЕНИЕ

### О проведении годового Общего собрания акционеров Открытого акционерного общества “Старокулаткинский комбикормовый завод”

*/место нахождения: 433931, Российская Федерация, Ульяновская область, Старокулаткинский район, с.Ст.Мостяк*

**УВАЖАЕМЫЙ АКЦИОНЕР!**

Сообщаем Вам, что Совет директоров Открытого акционерного общества “Старокулаткинский комбикормовый завод” (далее “Общество”) на своем заседании 23 мая 2017 года (Протокол №1 от 23 мая 2017 года) принял решение о созыве годового Общего собрания акционеров Общества (далее “собрания”) и проведение его в форме собрания (совместного присутствия акционеров для обсуждения вопросов повестки дня и принятия решений по вопросам, поставленным на голосование) 29 июня 2017 года в 16 часов 00 минут (время начала собрания) по адресу (места проведения собрания): Российская Федерация, Ульяновская область, Старокулаткинский район, с.Ст. Мостяк, здание администрации.

Совет директоров Общества определил 29 июня 2017 года датой составления списка лиц, имеющих право на участие в годовом Общем собрании акционеров Общества.

Дата и время начала регистрации лиц, имеющих право на участие в собрании: 29 июня 2017 года в 15 часов 30 минут. Регистрация лиц, имеющих право на участие в собрании, осуществляется по адресу места проведения собрания.

Регистрация лиц, имеющих право на участие в собрании, не зарегистрировавшихся для участия в собрании до его открытия (времени начала собрания), оканчивается не ранее завершения обсуждения последнего вопроса повестки дня собрания, по которому имеется кворум.

**Повестка дня собрания.**

1. О порядке ведения (Регламенте) годового Общего собрания акционеров Общества.
2. Утверждение годового отчета Общества, годовой бухгалтерской отчетности Общества, в том числе отчетов о прибылях и об убытках (счетов прибылей и убытков) Общества, а также распределение прибыли (в том числе выплата (объявление) дивидендов) и убытков Общества по результатам 2016 финансового года.
3. Избрание членов Совета директоров.
4. Об избрании Ревизора Общества.
5. Об утверждении аудитора Общества.

С информацией (материалами), подлежащей (ими) предоставлению при подготовке к проведению собрания можно ознакомиться с 26 мая 2017 года по 26 июня 2017 года ежедневно с 08 часов 00 минут до 17 часов 00 минут по адресу: Российская Федерация, Ульяновская область, Старокулаткинский район, с Ст.Мостяк, приемная Генерального директора Общества (единоличного исполнительного органа Общества), а также во время проведения собрания в дату его проведения – 29 июня 2017 года по месту его проведения.

Условия участия лиц, имеющих право участвовать в собрании.

В случае передачи акций после даты составления списка лиц, имеющих право на участие в собрании. И до даты проведения собрания, акционер обязан выдать приобретателю доверенность на голосование с указаниями приобретателя акций. Указанное правило применяется также к каждому последующему случаю передачи акций.

В собрании могут принимать участие:

* лица, включенные в список лиц, имеющих право на участие в собрании;

* лица, к которым права на акции указанных выше лиц перешли в порядке наследования или реорганизации;

* представители всех указанных выше лиц, действующие на основании доверенности на голосование или закона.

Акционеры (их представители) должны иметь при себе документ, удостоверяющий личность.

Полномочия представителей акционеров – физических лиц должны быть подтверждены доверенностью, заверенной нотариально, либо иным способом, установленным Гражданским кодексом Российской Федерации. Полномочия представителей акционеров – юридических лиц должны быть подтверждены надлежащим образом оформленной доверенностью либо документами, подтверждающими права представителя действовать без доверенности от имени юридического лица.

Доверенность на голосование должна содержать следующие сведения о предоставленном и представителю:

* физическом лице;

фамилия, имя, отчество, данные документа, удостоверяющего личность (серия и (или) номер документа, дата и место его выдачи, орган, выдающий документ);

* юридическом лице: полное фирменное наименование, место нахождения, дата внесения в Единый государственный реестр юридических лиц, основной государственный регистрационный номер, ИИН (идентификационный номер налогоплательщика), КПП (код причины постановки на налоговый учет). **Телефон для справок: (84249)2-29-95.**

**Совет директоров Общества.**

## Меры социальной поддержки ветеранам боевых действий

Меры социальной поддержки по оплате жилого помещения предоставляются по федеральному закону в размере 50% от суммы фактических расходов начисленных исходя из общей площади жилого помещения. Меры социальной поддержки распространяются на членов семьи, совместно проживающих с льготником.

Меры социальной поддержки по региональному закону предоставляются с 01.01.2013 г. ветеранам боевых действий, достигших возраста, дающего право на пенсию по старости. Меры социальной поддержки распространяются на членов семьи, совместно проживающих с льготником.

1) Например: семья из 3-х человек , один из которых ветеран боевых действий (возраст 45 лет). Общая площадь жилого помещения 68 кв.м. Компенсация на оплату жилого помещения будет начислена на 3 человек.

Начислено к оплате : содержание жилого помещения -1450,00 руб, капитальный ремонт -353,60 руб., отопление -2120,00 руб.,- электроэнергия-220,00 руб., газ -71,96 руб., ХВС -306,00 руб., ГВС- 800,00 руб., отведение сточных вод-160,00 руб., ТКО-100,00 руб.. ИТОГО: 5581,56 руб.

Расчет ЕДК на оплату ЖКУ :

- содержание жилого помещения-1450,00 руб.*50%=725,00 руб.

- капитальный ремонт-353,60 руб.*50%= 176,80 руб.

ИТОГО : 901,80 руб.

2) Например : семья из 4-х человек, один из которых ветеран боевых действий (возраст 65 лет).Общая площадь жилого помещения 72 кв.м. Компенсация на оплату жилого помещения и коммунальных услуг будет начислена на 4 человек.

Начислена к оплате : содержание жилого помещения -526,00 руб., отопление -2500,00 руб., электроэнергия -420,00 руб., газ -108,56 руб., ХВС-336,00 руб., ГВС- 800,00 руб., отведение сточных вод-280,00 руб., ТКО -100,00 руб.. ИТОГО: 5070,56 руб.

Расчет ЕДК на оплату жилого помещения по федеральному законодательству:

-содержание жилого помещения -526,00 руб.*50%=263,00 руб.

ИТОГО: 263,00 руб.

Расчет ЕДК на оплату коммунальных услуг по региональному законодательству:

-отопление-2500,00 руб.*50%= 1250,00 руб.,

-электроэнергия-420,00 руб.*/50%=210,00 руб.,

-газ-108,56 руб.*50%=54,28 руб.,

-ХВС-336,00 руб.*50%=168,00 руб.

-ГВС-800,00 руб.*50%=400,00 руб.

- отведение сточных вод-280,00 руб.*50%=140,00 руб.

ТКО-100,00 руб.*50%=50,00 руб.

ИТОГО: 2272,28 руб.

ОБЩАЯ сумма компенсации : 263,00+2222,28= 2485,28 руб.

# О присвоении звания "Ветеран труда Ульяновской области"

Законом Ульяновской области от 01.08.2014 №115-ЗО «О внесении изменения в статью 4 Закона Ульяновской области «О звании «Ветеран труда Ульяновской области» предусмотрены следующие основания для присвоения звания «Ветеран труда Ульяновской области»:

1. наличие наград Ульяновской области и (или) наград государственных органов Ульяновской области;
2. трудовой стаж не менее 40 лет (для мужчин) и 35 лет (для женщин);
3. три четверти вышеуказанного трудовой деятельности должно осуществляться на территории Ульяновской области (т.е. для мужчин – 30 лет, для женщин – 26 лет 3 месяца).

21.04.2016 года постановлением Правительства Ульяновской области

№ 173-П «О внесении изменения в постановление Правительства Ульяновской области от 04.02.2008 №41-П» действующий перечень наград Ульяновской области и наград государственных органов Ульяновской области дополнен Почётной грамотой Законодательного Собрания Ульяновской области, утверждённой постановлением Законодательного Собрания Ульяновской области от 25.12.2014 №1504/28-5.

Перечень наград, наличие которых необходимо для присвоения гражданину звания «Ветеран труда Ульяновской области»:

- звание «Почётный гражданин Ульяновской области»;

- орден «За проявленное мужество»;
- знак отличия «За заслуги перед Ульяновской областью»;

- медали Ульяновской области: медаль Почёта, медаль Дружбы народов, медаль «За заслуги в охране общественного порядка», медаль Н.М. Карамзина;

- почётные знаки Ульяновской области: «За веру и добродетель», «Материнская слава», «Отцовская слава»,

- почётные звания Ульяновской области:

«Заслуженный архитектор Ульяновской области», «Заслуженный деятель науки и техники Ульяновской области», «Заслуженный предприниматель Ульяновской области», «Заслуженный работник дорожного хозяйства Ульяновской области», «Заслуженный работник жилищно-коммунального хозяйства Ульяновской области», «Заслуженный работник здравоохранения Ульяновской области», «Заслуженный работник культуры Ульяновской области», «Заслуженный работник лесного хозяйства Ульяновской области», «Заслуженный работник образования Ульяновской области», «Заслуженный работник пищевой и перерабатывающей промышленности Ульяновской области», «Заслуженный работник правоохранительной системы», «Заслуженный работник промышленности Ульяновской области», «Заслуженный работник противопожарной службы Ульяновской области», «Заслуженный работник сельского хозяйства Ульяновской области», «Заслуженный работник социальной защиты населения Ульяновской области», «Заслуженный работник средств массовой информации Ульяновской области», «Заслуженный работник сферы информационных технологий и связи Ульяновской области», «Заслуженный работник сферы молодежной политики Ульяновской области», «Заслуженный работник топливно-энергетического комплекса Ульяновской области», «Заслуженный работник торговли и бытового обслуживания Ульяновской области», « Заслуженный работник транспорта Ульяновской области», «Заслуженный работник физической культуры и спорта Ульяновской области», «Заслуженный спасатель Ульяновской области», «Заслуженный строитель Ульяновской области», «Заслуженный эколог Ульяновской области», «Заслуженный экономист Ульяновской области», «Заслуженный юрист Ульяновской области»,

- звание «Почётный работник государственных и муниципальных органов в Ульяновской области»;

- почётный знак Губернатора Ульяновской области «За безупречную службу»;

- знаки Губернатора Ульяновской области «За заботу о красоте родного края», «Семья, любовь, верность», «Надежда и опора», «За трудовую доблесть»;

- Почётный знак «За заслуги в законотворческой деятельности»;

- Почётная грамота Законодательного Собрания Ульяновской области, учреждённая постановлением Законодательного Собрания Ульяновской области от 25.12.2014 №1504/28-5 «Об учреждении Почётной грамоты Законодательного Собрания Ульяновской области».

Бәйрәм кайтавазы



# Соңгы кыңгырау, соңгы чыңлау





Россия Герое Рәфәгать Хәбибуллин исемен йөрткән Иске Кулаткы икенче номерлы урта мәктәбендә үткән Соңгы кыңгырау бәйрәме укучыларның, укытучыларның, әти-әниләрнең, кунакларның күңелләрендә матур хатирә буларак озак вакыт сакланыр.

Тантана узачак мәйдан алдан ук бәйрәмчә бизәлгән: шарлар, чыгарылыш сыйныф укучыларының фотолары белән зур банер. Кызлар, гадәттәгечә, мәктәп формасыннан, чәчләренә ак бантлар такканнар. Егетләр, әлбәттә, костюмнан иделәр. Күңелле дә, моңсу да бу мизгелләр егет-кызларга. Алар бу көннән яңа тормышка аяк басалар, алда яңадан-яңа сынаулар, олы тормыш юлы көтә.

Бәйрәмне мәктәпнең өлкән вожатые С.Ф. Нугаева һәм IX сыйныф укучысы Ришат Санжапов күтәренке рухта алып бардылар. РФнең Гимны яңгыраганнан соң, тантаналы линейканы мәктәп директоры Л.Р. Альбикова ачып җибәрде.

22 май көнне өлкә Губернаторы С.И. Морозов патриотик тәрбия бирүдә иң яхшы мәктәпләргә Җиңү байрагының күчермәсен тапшырды. Өлкәнең 8 мәктәбе арасында Рәфәгать Хәбибуллин исемен йөрткән Иске Кулаткы икенче номерлы урта мәктәбе дә бар иде. Шушы байракның күчермәсен X сыйныф укучылары демонстрацияләде. Лилия Ринатовна чыгарылыш сыйныф укучыларын ихластан бәйрәм белән котлады.

- Без, укытучылар, унбер ел дәвамында бер генә борчу да китермәгән, игелекле, ярдәмчел, кешелекле балаларыбыз белән ихлас күңелдән горурланабыз. Чыгарылыш имтиханнарын уңышлы тапшырып, югары уку йортларында да мәктәбебезнең абруен төшермичә, әти-әниләрегезнең йөзләренә кызыллык китермичә укуыгызны телим. Барыр юлларыгыз имин, сайлаган һөнәрләрегез гомер буе яратып эшләрлек булсын, балалар! – диде мәктәп директоры.

Район администрациясе Башлыгының кеше потенциалын үстерү буенча беренче урынбасары В.А. Деникаева мәктәпнең иң талантлы укучыларына өлкә Почет грамоталары тапшырды һәм чыгарылыш сыйныф укучыларына бәйрәм котлавын юллады.

– Бүген сез барыгыз да тормышның беренче этабын тәмамладыгыз. Бүгенге вакыйга – олы юлга беренче адым. Уңышлар сезгә, әти-әниләрегезне, укытучыларыгызны һәрвакыт сөендереп торыгыз. Онытмагыз, туган ягыбызны данлау, матурлау өлешчә сездән тора. Хәерле юллар, бәхетле киләчәк сезгә!

11 ел элек беренче тапкыр белем дөньясына аяк атлатучы, хәрефләрне танып, иҗекләп укырга өйрәтүче укытучылары Н.Р. Аделова һәм сыйныф җитәкчеләре Ә.Б. Заитова укучыларына мәктәп елларының һәркем өчен иң күңелле, иң матур онытылмас вакыт булуын искәрттеләр, имтиханнарын уңышлы тәмамлап, дөрес юл сайлауларын һәм киләчәктә туган мәктәпләренең, районның, гомумән, илебезнең чын патриотлары булып калуларын теләделәр.

Әти - әниләр исеменнән Рәшидә Усеева, Гөлсем Садыкова балаларга иң изге теләкләрен белдерделәр. Ә инде Радик Бакиев кызы Ясминә белән унберенчеләргә матур музыкаль чыгыш бүләк итте.

Беренче һәм башка сыйныф укучылары да унберенчеләр тарафына җылы сүзләр ирештерделәр. XI һәм I сыйныф укучыларының бергәләп флешмоб биюләре – бәйрәмгә ямь өстәде.

Соңгы сүзне XI сыйныф укучылары тотты. Алар кешелекле, гадел булырга, яхшыны яманнан аерырга өйрәткәннәре һәм тирән белем биргәннәре өчен укытучылар коллективына чын күңелдән рәхмәтләр белдерделәр һәм яраткан укытучыларын чәчәк бәйләмнәре белән күмделәр, матур музыкаль чыгышлар ясадылар. Ахырда XI сыйныф укучыларының теләкләре тормышка ашсын дип, күккә күгәрченнәр белән шарлар очырулары - бәйрәмнең кульминациясе иде.

Ниһаять, күңелләргә моңсу хисләр салып XI сыйныф укучылары Алсу Бакиева, Ильяс Садыйков һәм I сыйныф укучылары Артур Аксәнов һәм Сабина Насыйрова бу уку елында соңгы мәртәбә мәктәп кыңгыравын яңгыраттылар. Әлбәттә, бу мизгелдә күбесе күз яшьләрен тыя алмады.

**Әлфия ЯФАРОВА.**

# Чәчәккә төренгән бәйрәм



24 майда Иске Кулаткы беренче номерлы урта мәктәбендә дә Соңгы кыңгырау бәйрәме чыгарылыш класс укучылары өчен шатлыклы да, моңсу да булды. Шатлыклы, чөнки укучылар ул көнне урта белем алуга ирешеп мәктәпне тәмаладылар, моңсу чөнки алар бу мәктәп белән мәңгегә хушлаштылар инде.

Иртәнге 9 сәгатьтә матур киемнәр киенгән укучылар да, әти-әниләр дә мәктәп бинасы алдына җыелдылар. XI класс укучылары бу бәйрәмнең төп геройлары буларак, матур итеп бер рәткә тезелделәр.

Быел бу мәктәптән XI классны 25, IX классны 31 укучы тәмамлады. Район администрациясе Башлыгы И. А. Аблязов аларны район администрациясе һәм үз исеменнән чын күңелдән кайнар тәбрик итте һәм укучыларга югары уку йортларына укырга кереп, хыялларының чынга ашуын теләде.

Соңгы кыңгырау бәйрәмен X класс укучылары Элина Мавлютова һәм Руслан Бахтияров матур итеп алып бардылар.

XI класс укучыларының җитәкчеләре Г. Р. Курамшина, Р. А. Үмәрова үзләренең укучыларына мәктәпне тәмамлау уңаеннан гел изге теләкләрен генә әйттеләр. Җылы теләкләргә шулай ук укытычылар Х. Б. Усманова һәм С. М. Атауллина да кушылдылар.

Матур чәчәкләргә күмелгән бәйрәм дәвам итте. Чыгарылыш класс укучыларының вальс биюләре, матур җырлар башкарулары күңелләрне тетрәндерде һәм әти-әниләрне дә мәктәп елларына алып кайтты, сыман. Укучыларның төрле төстә зәңгәр күккә шарлар очырулары - мәктәп белән хушлашуны хәтерләтте.

Әти-әниләр дә, мәктәпнең I класс укучылары да чыгышлар ясап, чыгарылыш сыйныф укучыларына изге теләкләр генә җиткерделәр.

Теләкләр кабул булсын һәм XI класс укучыларына уңышлы итеп имтиханнарын тапшырып, югары уку йортларына укырга керергә насыйп булсын иде.

**Рөстәм АРИФУЛЛИН.**

# Ватанны сакларга әзерләнәләр

25 май көнне, үзәк стадионга килеп кергәндә, төрле яшьтәге егет-кызлар шау-гөр килде: кем йөгерә, кем сикерә иде. Ул көнне 11-15 яшьлек мәктәп укучылары ГТО нормативлары тапшырдылар.

ГТО – хезмәт һәм оборонага әзер (“Готов к труду и обороне”) дигәнне аңлата. Кайчандыр гадәти булып саналган ГТО нормативлары бүген башкачарак күзалланса да, асылы шул ук калды – сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау, туган якка, хезмәткә мәхәббәт тәрбияләү. Әлеге максатларны чынга ашыруның иң яхшы юлы – яңалыкны яшь буын аша гамәлгә кертү.

Бу көнне балалар торып озынлыкка сикерүдә, туп ыргытуда, идәннән күтәрелүдә, озын һәм кыска дистанцияләргә чабышуда, турниктан күтәрелүдә көчләрен сынаштылар.



Нәтиҗәдә, 11-12 яшьлек егетләр арасында өченче дәрәҗәдә Булат Ахтәмов (Иске Кулаткы беренче номерлы урта мәктәбе), Илнур Узбеков, Рамис Рәхмәтуллин (Иске Кулаткы икенче номерлы урта мәктәбе) җиңү яуладылар.

Әлеге категориядә кызлар арасында Алина Сәйфетдинова (Иске Атлаш урта мәктәбе), Мария Мальцева (Иске Кулаткы икенче номерлы урта мәктәбе), Юлия Абдуллина (Урта Терешка урта мәктәбе) иң осталары булдылар.

13-15 егетләр арасында дүртенче дәрәҗәдә Булат Бекеров (Иске Кулаткы икенче номерлы урта мәктәбе), Марсель Сафаров, Илдар Рафиков (Иске Атлаш урта мәктәбе) уңышларга яуладылар.

Әлеге төрдә кызлар арасында Гүзәл Салихова (Иске Мостяк урта мәктәбе), Алина Ахмедова (Иске Кулаткы беренче номерлы урта мәктәбе), Эльнара Хамзина (Мосеевка төп мәктәбе)югары күрсәткечләргә ирештеләр.

Район фестивале нәтиҗәләре буенча балаларга ГТО разрядлары биреләчәк.

**Иршат САЛИХОВ,**
**Иске Кулаткы балалар һәм яшүсмерләр спорт мәктәбе директоры.**

# Милли тормыш һәм дин

Быел 18-20 майда Казан шәһәрендә Бөтенроссия татар дин әһелләренең VIII форумы булып узды. Ил күләмендә танылган шушы олы чарада безнең искекулаткылылар да зур делегацияләрнең берсе булып катнаштылар.

18 майда төнге 2 сәгатьтә мөселманнарыбыз район мөхтәсибе Рамазан хәзрәт Юмангулов җитәкчелегендә Татарстан Президенты бүләк иткән куәтле автобуста Казан шәһәренә таба юл алды. Алар мөсафир буларак иртәнге намаз юлда барганда, автобуста, ук укылды. Догалар кылып, табигатьнең матурлыгына карап, хозурлыгына сокланып, юлыбызның озынлыгын сизми дә калдык һәм без иртәнге 9 сәгатьтә Казан шәһәренә килеп җиттек. Бөтендөнья татар конгрессы бинасында теркәлү ясалгач, делегацияләр "Татарстан" кунакханәсенә урнаштылар. Ә инде төштән соң секцияләр утырышлары булды.



Секцияләр утырышларында "Ислам дине һәм татар халкының милли үзенчәлеге", "Болгар Ислам академиясе-милли рухи фикерне торгызу үзәге", "Мәчет һәм татар гаиләсе", "Ислам дине һәм күпкырлы матбугат" дигән темалар каралдылар. Безнең искекулаткылылар бүленешеп, һәрбер секциядә активлык күрсәттеләр. Иске Кулаткы районының мөхтәсибе Рамазан хәзрәт Юмангулов, Иске Кулаткы эшчеләр поселогы "Сафия" мәчетенең баш имамы Ринат хәзрәт Бәширов секцияләрдә эчтәлекле чыгышлар ясадылар.

"Мәчет һәм татар гаиләсе" дигән секция утырышы мөселманнарны тәрбияләү буенча иң мөһимнәрдән саналды дип әйтсәк, һич ялгыш булмас. Анда Татарстанның баш казые, Балтач районы имам мөхтәсибе Җәлил хәзрәт Фазлыев чыгыш ясап: "Гаилә булганда гына милләт бар. Гаиләдә тәртип булганда гына милләттә тәртип була", – дип белдерде.

Секция барышында Башкортстанның Борай районы имам мөхтәсибе Рифат хәзрәт Зарипов та үзенең акыллы фикерләре белән уртаклашты. Муллаларны мәктәпләр белән эшләргә өндәде. "Ай саен бер мәртәбә сыйныф сәгатьләрендә балаларга ислам дине нигезләре хакында мәгълүмат бирүне җайга салырга иде. Тәрбия сәгатьләрендә иман, әхлак турында сөйли алсак, нәтиҗәсе булмый калмас",- диде күрше республикадан килгән хәзрәт.



"Ислам дине һәм татар халкының милли үзенчәлеге" дигән секция утырышында Иске Кулаткы районының мөхтәсибе Рамазан хәзрәт Юмангулов чыгыш ясады. Ул мөселманнар каршында "Кулаткы укулары"ның дини тәрбия бирүдә үзенчәлеге турындагы теманы ачык итеп яктыртты. Аның чыгышына Казанның 1000 ел исемендәге югары мөселман мәдрәсәсе ректоры Ильяс хәзрәт Җиһаншин да югары бәя бирде.

Секцияләр утырышында илебезнең төрле төбәкләреннән килгән мөселман кардәшләребез динебезне үстерү турында төрле чыгышлар ясадылар һәм пленар утырышка үзләренең тәкъдимнәрен әзерләделәр.

Шул ук көнне икенде намазы, кичке аштан соң форумда катнашучылар Галиәскәр Камал исемендәге театрда Илдар Юзеевның "Ак калфагым төшердем кулдан" исемле спектаклен карадылар.

19 май, җомга көнне, иртәнге 10 сәгатьтә "Милли тормыш һәм дин" VIII Бөтенроссия татар дин әһелләре форумының пленар өлеше башланды. Анда илебезнең 68 төбәгеннән 957 делегат катнашты. Алар арасында иң ерактан Саха (Якутия), Кырым республикаларыннан, Амур, Магадан өлкәләреннән мөселманнар бар иде. Исәбе буенча 140 кешелек делегация Башкортстаннан булды һәм ул иң зурлардан саналды.

Пленар утырыш Коръән сүрәләрен уку белән башланды һәм аны Рәсәй ислам университетының ректоры Рафик хәзрәт Мухамметшин алып барды. Президиумда Бөтендөнья татар конгрессының рәисе Ринат Закиров, Татарстанның баш мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин һәм башка шәрәфле мөселманнар урын алган иделәр.

Озак та үтми илебезнең төрле төбәкләреннән килгән дин әһелләре бер-бер артлы трибунадан чыгышлар ясый башладылар.

Алар арасында Сарытау өлкәсе баш мөфтиенең урынбасары Рушан хәзрәт Сәйфетдиновның, Татарстан республикасы фәннәр академиясе, татар энциклопедиясе һәм төбәкләр өйрәнү институты директоры Искәндәр Аяз улы Гыйлаҗевның , Казанның 1000 ел исемендәге югары мөселман мәдрәсәсе ректоры Ильяс хәзрәт Җиһаншинның, Новосибирск өлкәсе Кыштовка районы имам хатыйбы Якуп хәзрәт Вахитовның, Курган өлкәсе Өчкүл авылы имамы Рөстәм хәзрәт Шакировның, Пенза өлкәсе мөселманнары Диния нәзарәте рәисе урынбасары Йосыф хәзрәт Бибарсовның һәм башкаларның чыгышлары актуаль булып саналдылар. Биредә шулай ук 18 майда секцияләрдә күтәрелгән дини мәсьәләләрне чишү турында тәкъдимнәр әйтелде. Чыгыш ясаучылар шулай ук имамнарның халык белән тыгыз элемтәдә торырга, мәхәлләнең төп нәтиҗәсе, милли үзенчәлекне саклап калу, гошер садакасын бирү, шәҗәрә төзү фәнен булдыру кирәклеге турында һәм башка темаларны ачык итеп яктырттылар.

Пленар утырышның беренче өлеше тәмамлангач, форумда катнашучы барлык мөселманнар Кол Шәриф мәчетенә Җомга намазы укырга бардылар. Ил күләмендә танылган бу изге гыйбадәтханә үзенең эченә 1500 мең кешене сыйдыра ала һәм ул көнне биредә мөселманнар шыгрым тулы иде. Җомга намазын Татарстан республикасының баш мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин укытты һәм без изге гыйбадәтләребезне кылып, Кол Шәриф мәчетенә хәер-сәдакаларыбызны да тапшырдык.

Изге ният кылганнан соң Казан Кремлендә экскурсиядә булып, истәлеккә фотоларга да төштек.

Форумның пленар утырышының икенче өлеше башланыр алдыннан Г. Камал театрының фойесында Халык осталары һәм һөнәрчеләре җитештергән товарлар, китаплар күргәзмәсе белән якыннан танышып чыктык. Халык осталары җитештергән музыка уен коралларының аһәңле итеп яңгыраулары күңелләребезне татар моңнары дөньясына алып керде һәм ялыкканыбызны да оныттырды бугай.

Кичке 16 сәгатьтә пленар утырышның икенче өлеше башланды. Бу юлы безне Татарстанның Президенты Рөстәм Нуралиевич Миңнеханов кайнар сәламләде.

"Хөрмәтле милләтәшләрем, дин кардәшләрем! " Бөтендөнья татар дин әһелләре форумында бергә очрашу милләтебез, мөселманнарыбыз өчен олы чара. Соңгы елларда уртак тел табып, мөһим эшләр башкарганы елдан-ел ачык күренә бара. Моның турында илебезнең төрле төбәкләрендә торгызылган гыйбадәтханәләр, мәчетләр турыдан-туры сөйлиләр. Татарстаннан читтә яшәүче милләттәшләребезнең уңышларына да чын күңелдән шатланабыз. Алар белән киләчәктә дә бергә очрашып дини йолаларыбызны бергә башкарырга насыйп итсен иде.

Р. Н. Миңнеханов үзенең чыгышын тәмамлаганнан соң илебезнең төрле төбәкләрендә яшәүче дин әһелләренә казанышлары өчен Татарстан республикасы Президенты исеменнән Рәхмәт хатлары һәм башка бүләкләр тапшырды.



Аннан соң сүзне Русия мөселманнарының Үзәк диния нәзарәте рәисе, Баш мөфтие Тәлгать Таҗетдин алды:

- Безнең илдә 193 милләт халкы яши һәм алар арасында тынычлыкны, ризалыкны булдыру - безнең изге бурычыбыз. Эшләребез белән күркәм булыйк, хикмәт белән, күркәм вәгазь белән, тыгыз элемтәдә яшәп, халыкны дингә өндик –диде.

Ул шулай ук экстремизмга каршы көрәш алып бару һәм аны булдырмас өчен үзенең акыллы фикерләрен әйтте.

Рәсәй ислам университетының ректоры Рафик хәзрәт Мухамметшин трибунадан чыгыш ясап, быел көзгә югары уку йорты буларак Болгар ислам академиясе үзенең эшен башлап җибәрүе турында белдерде.

- Ислам академиясе ачылгач, яшьләребез дини белемнәрен чит илләрдә түгел, ә үзебездә үзләштерәчәкләр, - диде ул.

Пленар утырышның икенче өлешендә шулай ук Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев гаилә, тәрбия, дини йолалар, хатын-кыз ана булырга тиеш, хәрам ризыктан тыелу дигән темаларны яктыртып кызыклы чыгышлар ясады.

Утырышны Бөтендөнья татар конгрессының рәисе Ринат Зиннурович Закиров дәвам итте.

- Бөтенроссия татар дин әһелләренең форумын сигезенче мәртәбә уздырабыз һәм ул Ислам динен, яшәү рәвешен үстерүдә, гаиләләрнең ныклыгын арттыруда зур әһәмияткә ия. Менә Бөтендөнья татар конгрессы оешуга да 25 ел булды һәм бу оешмада үзебезнең илдә, җир шарында 40 илдә яшәгән татарларны берләштерә. Иншалла, төрле күләмдә оештырылган Сабантуйларыбызда дини йолаларыбызга нигезләнеп, хәмерсез уза һәм анда бихисап милләтәшләребез зур теләк белдереп катнашалар. Киләчәктә дә форумнарыбыз мөселманнарыбызны берләштерер һәм безнең элемтәләребез бер-беребез белән тагын да ныгыр.



Пленар утырышның азагында "Милли тормыш һәм дин" VIII Бөтенроссия татар дин әһелләре форумының резолюциясе кабул ителде.

**Изге Болгар җирендә**

Без иртәнге 5 сәгатьтә Казан шәһәреннән Изге Болгар җиренә юл алдык. Бу сәяхәтебезнең озынлыгы 182 километр тәшкил итте һәм Кама елгасы аша узып 2,5 сәгать эчендә билгеләнгән урыныбызга килеп җиттек. Изге Болгар җыенда безнең белән Иске Кулаткыдан хатын-кызлар делегациясе дә булды.

Әлеге җыен 922 елда ислам динен рәсми рәвештә кабул ителүгә багышланган иде. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, Татарстанның Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, РФнең Үзәк Диния нәзарәте рәисе, Россия Баш мөфтие Тәлгать Таҗетдин, Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисе Камил хәзрәт Сәмигуллин, Россия төбәкләреннән килгән мөфтиләр, имамнар бәйрәм чарасында катнашып кына калмады, алар көзгә ачылырга ниятләнгән Болгар ислам академиясе белән таныштылар, уку йортында белем бирү эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре буенча фикер алыштылар.

Һава торышы аяз, яңгырсыз, булганга, Болгар Җыенына бихисап күп халык килгән иде. Аның мәдәни программасын Г. Камал театры артистлары Фәнис Җиһанша һәм Алсу Вәҗиева алып барды. Алып баручылар тарафыннан Болгар академиясенең татар халкының мәшһүр галим мәгърифәтчеләре Батырша, Шиһабетдин Мәрҗәни, Муса Бигиев һәм башкаларның традицияләрен дәвам иттерерлек белгечләр әзерли торган уку йорты булачагына ышаныч белдерде. Фәнис Җиһанша 2016 елның 21 маенда Болгар ислам академиясенә беренче нигез ташы салынганлыгын искәртте.

Җыенда катнашучыларга Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов мөрәҗәгать итте.

- Болгар ислам академиясе дини тәгълиматчылар үзәге булырга тиеш. Болай булачагына шик юк, моның өчен бөтен шартлар тудырылган. Безнең бабаларыбыз шушы җирне, динне сайлаган икән, традиция, гореф - гадәтләрне сакларга тиешбез, - дип белдерде республика җитәкчесе.

Минтимер Шәймиев Җыенда катнашучыларны һәм Җыен кунакларын сәламләп: "Соңгы елларда Болгарда башкарылган эшләр күңелебезгә хуш килә. Бу эшләр могҗиза бит. Халкыбызның рухи көче турында сүз бара. Болгар академиясен булдыру дөрес фикер булды. Узган елда беренче ташка нигез салган идек. Быел сентябрьдә ачарбыз, дип хыялланабыз гына түгел, эшне башларбыз, дип ышанабыз. Иң мөһиме шартлар тудырылган", - дип билгеләп узды Дәүләт Киңәшчесе.

Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин үзенең чыгышында: "Яңа академиядән дә, иншалла, зур галимнәр чыгар. Ул бердәмлек диндары булыр, чөнки таркаулык өчен бернинди сәбәп юк. Аллаһыбыз бер, пәйгамбәребез бер, динебез бер, китабыбыз бер, хәтта милләтебез дә бер",-дип белдерде мөфти.

Җыенда шулай ук Россия мөселманнары Диния нәзарәте рәисе урынбасары Рушан Аббәсов, Төньяк Кавказ мөселманнары координацион Советы рәисе, Чечня республикасы мөфтие Сәлах Мәҗиев та чыгыш ясадылар. Алар бу Җыенга, Болгар җирендә Ислам академиясенең торгызылуына зур бәя бирделәр.

Искекулаткылыларның Бөтенроссия татар дин әһелләре форумнарында һәм Изге Болгар Җыеннарында катнашуларын оештыруда район Башлыгы Эдуард Әнвәрович Ганеевның роле зур аның тырышлыгы нәтиҗәсендә районыбыз авылларында яңадан яңа мәчетләр калкып чыктылар һәм бихисап мөселманнарыбыз дин юлына бастылар. Шушы изге гамәлләре өчен без Казан шәһәрендә форумда һәм Болгар Җыенында катнашучылар район Башлыгы Э. Ә. Ганеевка олы рәхмәтләребезне белдерәбез.

**Рөстәм АРИФУЛЛИН.**
**Иске Кулаткы – Казан-Изге Болгар.**

**РОССИЙСКАЯ ФЕДЕРАЦИЯ**
**Совет депутатов муниципального образования**
**«Старокулаткинский район»**
**Ульяновской области**

**РЕШЕНИЕ**

26. 05. 2017 г. р.п. Старая Кулатка № 9/3

Об утверждении перечня муниципального имущества муниципального образования «Старокулаткинский район» Ульяновской области, свободного от прав третьих лиц (за исключением имущественных прав субъектов малого и среднего предпринимательства), которое может быть использовано только в целях предоставления его во владение и (или) пользование на долгосрочной основе (в том числе по льготным ставкам арендной платы) субъектам малого и среднего предпринимательства и организациям, образующим инфраструктуру поддержки субъектов малого и среднего предпринимательства

В соответствии с Федеральным законом от 22.07.2008 N 159-ФЗ "Об особенностях отчуждения недвижимого имущества, находящегося в государственной собственности субъектов Российской Федерации или в муниципальной собственности и арендуемого субъектами малого и среднего предпринимательства", частью 4 статьи 18 Федерального закона от 24 июля 2007 г. N 209-ФЗ "О развитии малого и среднего предпринимательства в Российской Федерации, Совет депутатов муниципального образования «Старокулаткинский район» Ульяновской области

**РЕШИЛ:**

1. Утвердить Перечень имущества муниципального образования "Старокулаткинский район" Ульяновской области, свободного от прав третьих лиц (за исключением имущественных прав субъектов малого и среднего предпринимательства), которое может быть использовано только в целях предоставления его во владение и (или) пользование на долгосрочной основе (в том числе по льготным ставкам арендной платы) субъектам малого и среднего предпринимательства и организациям, образующим инфраструктуру поддержки субъектов малого и среднего предпринимательства, согласно приложению к настоящему решению.
2. Контроль за исполнением данного решения возложить на Главу администрации муниципального образования «Старокулаткинский район».
3. Настоящее решение вступает в силу с момента подписания, подлежит официальному опубликованию и размещению на официальном сайте муниципального образования «Старокулаткинский район» Ульяновской области в сети «Интернет» не позднее 15 дней со дня его принятия.

Глава
муниципального образования
«Старокулаткинский район» Э.А. Ганеев.

УТВЕРЖДЕН
Решением Совета депутатов муниципального образования
«Старокулаткинский район» 25.05.2017 г. № 9/3

**ПЕРЕЧЕНЬ**
**ИМУЩЕСТВА МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ "СТАРОКУЛАТКИНСКИЙ РАЙОН" УЛЬЯНОВСКОЙ ОБЛАСТИ, СВОБОДНОГО ОТ ПРАВ ТРЕТЬИХ ЛИЦ (ЗА ИСКЛЮЧЕНИЕМ ИМУЩЕСТВЕННЫХ ПРАВ СУБЪЕКТОВ МАЛОГО И СРЕДНЕГО ПРЕДПРИНИМАТЕЛЬСТВА), КОТОРОЕ МОЖЕТ БЫТЬ ИСПОЛЬЗОВАНО ТОЛЬКО В ЦЕЛЯХ ПРЕДОСТАВЛЕНИЯ ЕГО ВО ВЛАДЕНИЕ И (ИЛИ) ПОЛЬЗОВАНИЕ НА ДОЛГОСРОЧНОЙ ОСНОВЕ (В ТОМ ЧИСЛЕ ПО ЛЬГОТНЫМ СТАВКАМ АРЕНДНОЙ ПЛАТЫ) СУБЪЕКТАМ МАЛОГО И СРЕДНЕГО ПРЕДПРИНИМАТЕЛЬСТВА И ОРГАНИЗАЦИЯМ, ОБРАЗУЮЩИМ ИНФРАСТРУКТУРУ ПОДДЕРЖКИ СУБЪЕКТОВ МАЛОГО И СРЕДНЕГО ПРЕДПРИНИМАТЕЛЬСТВА**

| № | Наименование объекта | Адрес: Ульяновская область, Старокулаткинский район… | Характеристика объекта | Цель использования | Примечание (в том числе по обременению) |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Здание Кузнечного цеха | р.п. Старая Кулатка, ул. Красногвардейская, д. 16 | назначение: нежилое, 1-этажный, общей площадью 391,2 кв.м., инв. №027528, лит. Б, год ввода 1963 89/1000 доли земельного участка, категория земель: земли населенных пунктов, разрешенное использование – под производственной базой, площадью 26088 кв.м. | Склад, производство промышленных и сельскохозяйственных товаров | Используется по договору аренды |
| 2 | Здание Базы материально-технического обслуживания тракторов | р.п. Старая Кулатка, ул. Красногвардейская, д. 16 | назначение: нежилое, 1-этажный, общей площадью 422,6 кв.м., инв. №027528, лит. А, год ввода 1980 96/1000 доли земельного участка, категория земель: земли населенных пунктов, разрешенное использование – под производственной базой, площадью 26088 кв.м. | Склад, производство промышленных и сельскохозяйственных товаров | отсутствует |
| 3 | Здание Автогаража | р.п. Старая Кулатка, ул. Красногвардейская, д. 16 | назначение: нежилое, 1-этажный, общей площадью 1038,7 кв.м., инв. №027528, лит. Е, год ввода 1980 235/1000 доли земельного участка, категория земель: земли населенных пунктов, разрешенное использование – под производственной базой, площадью 26088 кв.м | Склад, производство промышленных и сельскохозяйственных товаров | отсутствует |
| 4 | Здание столярного цеха | р.п. Старая Кулатка, ул. Красногвардейская, д. 16 | назначение: нежилое, 1-этажный, общей площадью 133 кв.м., инв. №027528, лит. К, год ввода 1981 30/1000 доли земельного участка, категория земель: земли населенных пунктов, разрешенное использование – под производственной базой, площадью 26088 кв.м. | Склад, производство промышленных и сельскохозяйственных товаров, техники | отсутствует |
| 5 | Здание мельницы | р.п. Старая Кулатка, ул. Красногвардейская, д. 4 | назначение: нежилое, 1-этажный, общая площадью 234,4 кв.м., инв. №9229-1, лит. А, А1, А2, А3 год ввода 1964 и земельный участок , категория земель: земли населенных пунктов, разрешенное использование: под зданием мельницы, площадь 743 кв.м. | мельница | отсутствует |

**РОССИЙСКАЯ ФЕДЕРАЦИЯ**
**Совет депутатов муниципального образования**
**«Старокулаткинский район»**
**Ульяновской области**

**РЕШЕНИЕ**

26.05. 2017 г. р.п. Старая Кулатка № 9/4

Об утверждении прогнозного плана приватизации муниципального имущества муниципального образования «Старокулаткинский район» на 2017 -2018 годы

В соответствии с Федеральным законом от 21.12.2001 г. N 178-ФЗ «О приватизации государственного и муниципального имущества», Уставом муниципального образования «Старокулаткинский район», Положением о порядке владения, пользования и распоряжения имуществом, находящимся в собственности муниципального образования «Старокулаткинский район», Совет депутатов муниципального образования «Старокулаткинский район» Ульяновской области

**РЕШИЛ:**

1. Утвердить прогнозный план приватизации муниципального имущества муниципального образования «Старокулаткинский район» Ульяновской области на 2017-2018 годы согласно приложению к настоящему решению.
2. Признать утратившим силу решение Совета депутатов муниципального образования «Старокулаткинский район» от 25.12.2015 года №33/2 «Об утверждении прогнозного плана приватизации муниципального имущества, находящегося в муниципальной собственности муниципального образования «Старокулаткинский район» Ульяновской области на 2016 -2017 годы».
3. Контроль за исполнением данного решения возложить на Главу администрации муниципального образования «Старокулаткинский район».
4. Настоящее решение вступает в силу с момента подписания, подлежит официальному опубликованию (обнародованию), размещению на официальном сайте муниципального образования «Старокулаткинский район» Ульяновской области в сети «Интернет».

Глава
муниципального образования
«Старокулаткинский район» Э.А. Ганеев.

**УТВЕРЖДЕН**
**Решением Совета депутатов муниципального образования**
**«Старокулаткинский**
**район» 25.05.2017 г. № 9/4**

**ПРОГНОЗНЫЙ ПЛАН**
**ПРИВАТИЗАЦИИ МУНИЦИПАЛЬНОГО ИМУЩЕСТВА МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «СТАРОКУЛАТКИНСКИЙ РАЙОН» УЛЬЯНОВСКОЙ ОБЛАСТИ**
**НА 2017 -2018 ГОДЫ**

**Раздел I. Основные направления реализации политики в сфере приватизации муниципального имущества муниципального образования «Старокулаткинский район» Ульяновской области в 2017-2018 годах**

Настоящий прогнозный план приватизации муниципального имущества, находящегося в муниципальной собственности муниципального образования «Старокулаткинский район» Ульяновской области на 2017 -2018 годы (далее по тексту - План) разработан в соответствии с Гражданским кодексом Российской Федерации, Земельным кодексом Российской Федерации, Федеральным законом Российской Федерации от 06.10.2003 №131-ФЗ «Об общих принципах организации местного самоуправления в Российской Федерации», Федеральным законом Российской Федерации от 21.12.2001 №178-ФЗ «О приватизации государственного и муниципального имущества», Федеральным законом от 29.07.1998 года №135-ФЗ «Об оценочной деятельности в Российской Федерации», Федеральным законом Российской Федерации от 14.11.2002 №161-ФЗ «О государственных и муниципальных унитарных предприятиях», Постановлением Правительства Российской Федерации от 12.08.2002 №585 «Об утверждении Положения об организации продажи государственного или муниципального имущества на аукционе.

План устанавливает организационные и правовые основы преобразования отношений собственности посредством приватизации муниципального имущества муниципального образования «Старокулаткинский район» Ульяновской области, который понимается, как возмездное отчуждение находящегося в муниципальной собственности имущества (объектов приватизации) в собственность физических лиц и юридических лиц, не относящихся к государственной или муниципальной собственности.

Приватизация в 2017-2018 годах будет направлена прежде всего на решение следующих задач:
а) преобразование отношений собственности в интересах населения района;
б) удовлетворение потребностей населения в сфере торговли, услуг и общественного питания путем развития конкуренции;
в) привлечение внутренних и внешних инвестиций в экономику района;
г) улучшение платежного баланса муниципального образования «Старокулаткинский район» Ульяновской области в результате приватизации.

В указанных целях в Плане предусмотрены следующие приоритеты при осуществлении приватизации муниципального имущества:
а) оптимизация процессов использования, распоряжения и управления муниципальным имуществом, в том числе за счет сокращения бюджетных расходов;
б) сохранение объектов инженерной инфраструктуры, обеспечивающих жизнедеятельность района;
в) создание условий для развития рынка недвижимости;
г) поддержка субъектов малого и среднего предпринимательства.

**Приоритеты в осуществлении приватизации муниципального имущества муниципального образования «Старокулаткинский район»**

1. Приватизация муниципального имущества муниципального образования Суворовский район в 2017-2018 годах будет проводиться в соответствии со следующими приоритетами:
- продажа низкодоходного имущества, возможности для эффективного управления которыми ограничены;
- обеспечение поступлений в бюджет района финансовых средств от приватизации муниципального имущества;
- уменьшение бюджетных расходов на управление экономикой, содержание муниципального имущества.

Перечень объектов, включенных в План приватизации, сформирован исходя из принципа целесообразности приватизации муниципального имущества. Указанный перечень не является окончательным. Он может быть дополнен по предложению главы Администрации муниципального образования «Старокулаткинский район» решением Совета депутатов муниципального образования "Старокулаткинский район" Приватизация зданий, строений и сооружений, а также объектов, строительство которых не завершено и которые признаны самостоятельными объектами недвижимости, осуществляется одновременно с отчуждением лицу, приобретающему такое имущество, земельных участков, занимаемых таким имуществом и необходимых для его использования, если иное не предусмотрено законодательством.

## Раздел II. Перечень объектов муниципального имущества муниципального образования «Старокулаткинский район» Ульяновской области, подлежащих приватизации в 2017-2018 годах

| № | Наименование объекта | Адрес: Ульяновская область, Старокулаткинский район… | Характеристика объекта | Способ приватизации |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Здание цеха ЖБИ, Здание профилактория для гаража, Здание автозаправочной станции и земельный участок | Усть - Кулатка, ул. Октябрьская, д.1-А. | Здание цеха ЖБИ, назначение: нежилое, 1-этажный с общей площадью 3028,8 кв.м., инв.№029499, лит. А,А1,А2<br>Здание профилактория для гаража, назначение: нежилое, 1 -этажный, общей площадью 867,2 кв.м., инв. № 029499, лит. Б,<br>Здание автозаправочной станции, назначение: нежилое, 1-этажный, общая площадь 6 кв.м,, инв. №029499, лит.В,<br>земельный участок, категория земель: земли промышленности, энергетики, транспорта, связи, радиовещания, телевидения, информатики земли для обеспечения космической деятельности, земли обороны, безопасности и земли иного специального назначения, разрешенное использование: Для производственных целей, площадь 25066 кв.м., | Аукцион с подачей предложений по цене в открытой форме |
| 2 | Здание МСО | р.п. Старая Кулатка, ул. Красногвардейская, д. 16 | назначение: нежилое, 2-этажный, общей площадью 811,9 кв.м., инв. №027528, лит. Д, год ввода 1969 184/1000 доли земельного участка, категория земель: земли населенных пунктов, разрешенное использование – под производственной базой, площадью 26088 кв.м. | Аукцион с подачей предложений по цене в открытой форме |
| 3 | Здание материального склада | р.п. Старая Кулатка, ул. Красногвардейская, д. 16 | назначение: нежилое, 1-этажный, общей площадью 278,8 кв.м., инв. №027528, лит. Ж, год ввода 1983 63/1000доли земельного участка, категория земель: земли населенных пунктов, разрешенное использование – под производственной базой, площадью 26088 кв.м. | Аукцион с подачей предложений по цене в открытой форме |
| 4 | Здание арматурного цеха | р.п. Старая Кулатка, ул. Красногвардейская, д. 16 | назначение: нежилое, 1-этажный, общей площадью 252,5 кв.м., инв. №027528, лит. Л, год ввода 1985 57/1000 доли земельного участка, категория земель: земли населенных пунктов, разрешенное использование – под производственной базой, площадью 26088 кв.м | Аукцион с подачей предложений по цене в открытой форме |
| 5 | Здание котельной | р.п. Старая Кулатка, ул. Красногвардейская, д. 16 | назначение: нежилое, 1-этажный, общей площадью 252,5 кв.м., инв. №027528, лит. М, год ввода 1983 57/1000 доли земельного участка, категория земель: земли населенных пунктов, разрешенное использование – под производственной базой, площадью 26088 кв.м. | Аукцион с подачей предложений по цене в открытой форме |
| 6 | Здание растворо-бетонного узла | р.п. Старая Кулатка, ул. Красногвардейская, д. 16 | назначение: нежилое, 1-этажный, общей площадью 223,8 кв.м., инв. №027528, лит. Н,Н1, год ввода 1969 51/1000 доли земельного участка, категория земель: земли населенных пунктов, разрешенное использование – под производственной базой, площадью 26088 кв.м. | Аукцион с подачей предложений по цене в открытой форме |
| 7 | Здание кирпичное под склад | р.п. Старая Кулатка, ул. Красногвардейская, д. 16 | назначение: нежилое, 1-этажный, площадь застройки 314,9 кв.м., инв. №027528, лит. П, год ввода 1973 72/1000 доли земельного участка, категория земель: земли населенных пунктов, разрешенное использование – под производственной базой, площадью 26088 кв.м. | Аукцион с подачей предложений по цене в открытой форме |
| 8 | Здание бани | р.п. Старая Кулатка, ул. Г.Тукая, 16 | назначение - нежилое здание, 1-этажный, общая площадь 250,8 кв.м., год ввода 1973, земельный участок , категория земель: земли населенных пунктов, разрешенное использование: под зданием бани, площадь 743 кв.м. | Аукцион с подачей предложений по цене в открытой форме |
| 9 | Здание локальной котельной для РОО, назначение-нежилое здание, 1 этажный | р.п. Старая Кулатка, ул. Пионерская, 10А | назначение - нежилое здание, 1-этажный, общая площадь 17,7 кв.м., год ввода 1973, земельный участок , категория земель: земли населенных пунктов, разрешенное использование: для строительства котельной РОО, площадь 236 кв.м. | Аукцион с подачей предложений по цене в открытой форме |

Ихтирамга лаек шәхесләр

# Хезмәте белән дан яулады

*Укытучы!*
*Сездәдер ул*
*йөрәкләрнең иң*
*олысы,*
*Сездәдер ул*
*йөрәкләрнең*
*иң җылысы,*
*Сезгә карап*
*сокланабыз*
*һәрчак,*
*Күңелләрдә туа*
*горурлык.*
*Рәхмәт сезгә,*
*әле ярый сез бар*
*Безгә үрнәк булып*
*торырлык.*

Һөнәрләрнең ниндиләре генә юк. Һәр кеше үзенә якынын сайлый ала. Һөнәрләрнең иң асылы - укытучы. Укытучы дигән бөек исемне һәрбер кеше дә йөртә алмый. Аның өчен табигать биргән зур илаһи көч, сабырлык, зирәклек һәм акыл тирәнлеге, өмет, ышаныч һәм ныклы иман кирәк. Гомер-гомергә укытучы маякчы, җитәкләүче, кеше гомеренең бизәкчесе булып санала. Ул бөтен гомерен яшь буынга белем һәм тәрбия бирүгә багышлый. Әлеге язмада гаҗәеп кешелекле, якты күңелле, гомер буе остаз да, үрнәк тә булып калган укытучы турында. Ул – Иске Кулаткы эшчеләр бистәсендә туып үскән һәм бөтен гомерен балаларга багышлаган укытучы-ветеран, мәгариф отличнигы Гөлҗиһан Сәлимҗановна Ахтәмова.



Гөлҗиһан Сәлимҗановна 1947елның 1 июнендә дөньяга килә. Ул яшьтән үк тырыш, эш сөючән бала булып үсә. Уңышлы гына мәктәпне тәмамлап, үз көче белән институтка керә. Мәктәптә укытучы булып эшли, ә читтән торып югары уку йортын тәмамлый. Аның бала чагы сугыштан соңгы авыр елларга туры килә.

Тырыш, тыйнак, эшчән кызны күрше егете Равил сизеп ала. Ул үзе дә шундый ук тырыш, булдыклы егет була. Гөрләтеп туй да ясыйлар һәм икәүләп тормыш йөген тарта башлыйлар. Гомер барышында 3 балалары дөньяга туа, аларны аякка бастырып, олы тормыш юлына чыгаралар. Олы кызлары Зөлфия әнисе юлыннан китеп, укытучы һөнәрен сайлады, Әлфия юристка укыды,ә уллары Илдарның белмәгән эше юк, ул җитмеш төрле һөнәр иясе дип әйтсәк, һич ялгыш булмас. Йорты тулы мал-туар, кош-корт, өйдә дә бөтен уңайлыклар тудырылган. Үзләре кебек эшчән, тырыш килене Гөлнара да туры килде.

Әти-әниләре балалары өчен үрнәк тә, зур терәк тә иде. Ләкин көтмәгәндә гаиләне олы хәсрәт чолгап ала – мәрхәмәтсез үлем әтиләрен үз кочагына ала. Гөлҗиһан апа бик каты хәсрәт, зур югалту кичерә. Ләкин тормыш дәвам итә. Авырлыкларны зур сабырлык белән җиңеп, сынмыйча-сыгылмыйча, кешеләрне һәм тормышны яратып, хезмәткә бирелеп яши Гөлҗиһан Сәлимҗановна.

Ул – бик үрнәк укытучы. Гадел һәм түземле, тыныч һәм ягымлы. Укучыларны ярата һәм аларның уңышларына сөенә, кайгыларын да уртаклаша. Дәресләрне дә аңлаешлы һәм күңелле итеп үткәрә ул. Аңламаган темаларны кат – кат аңлатырга да вакытын кызганмый. Аның белмәгән нәрсәсе юк, бөтен сорауларга җавап таба. Һәр укучының хәленә керә, булыша, аңлый.

Ул укучыларны бик күпкә өйрәтте. Яхшыны яманнан аерырга да, хезмәт һәм иҗат шатлыгын тоярга да, фикерләү сәләтен үстерергә дә. Укучылардан чын шәхес тәрбияләргә бөтен көчен бирде.

Укытучы булу җиңел түгел. Ул зур сабырлык, балаларга карата олы мәхәббәт һәм сайлаган һөнәргә карата чиксез ярату, тугрылык таләп итә.

Гөлҗиһан Сәлимҗановна дөньядагы барлык матур сыйфатларны үзенә туплаган. Ул йомшак күңелле, тырыш, сабыр, намуслы, ярдәмчел, олы йөрәкле, тирән белемле һәм хөрмәткә лаек укытучы.

Хөрмәтле Гөлҗиһан Сәлимҗановна! Без, Сезнең коллегаларыгыз, чын күңелдән истәлекле юбилеегыз белән тәбрик итәбез. Сезгә бәхетле, озын гомер, күтәренке кәеф, ныклы сәламәтлек, тыныч көннәр һәм өметле киләчәк телибез. Һәрвакыт шулай көчле рухлы һәм кешелекле, юмарт һәм ярдәмчел, олы җанлы, киң күңелле булып калыгыз. Киләчәктә дә дусларыгызның, хезмәттәшләрегезнең ихтирамын, туганнарыгызның кадер-хөрмәтен тоеп, тормыштан ямь табып яшәгез! Намуслы хезмәтегез өчен олы рәхмәтебезне һәм тирән ихтирамыбызны белдерәбез.

**Россия Герое Р.М. Хәбибуллин исемен йөрткән Иске Кулаткы икенче номерлы урта мәктәбе коллективы.**

**Хөрмәтле Гөлҗиһан Сәлимҗановна АХТӘМОВА!**

Сезне ихлас күңелдән матур юбилеегыз белән котлыйбыз. Сез 35 ел дәвамында укытучы хезмәтенә тугры булдыгыз. Гомерегезне балалар укытуга багышлап, киләчәк тормышка әзерләүгә алынган, шушы мактаулы эшкә бар күңелегезне, йөрәк җылыгызны салган, тынгысыз, көчле рухлы мөгаллимә идегез. Әлеге һөнәр, беренче чиратта, сабырлык, түземлек сорый. Икенчедән, балаларга карата олы мәхәббәт таләп итә. Чыннан да, балаларны чын күңелдән яраткан, аларга ярдәм итәргә ашыгучы, нык ихтыярлы кеше генә укытучы булып эшли. Безнең, укучыларыгызның, күңелләренә яхшылык орлыклары сибүче, яхшыны яманнан аерырга өйрәтүче, ныклы тәрбия бирүче сыйныф җитәкчебез идегез. Безгә кылган изгелекләрегезнең әҗерен күрергә насыйп булсын. Уй-теләкләрегез тиң, туар таңнарыгыз тыныч, саулыгыгыз ныклы, гомерегез бәхетле булсын! Сез - безнең йөрәк түребездә!

*Гомерләрегез булсын бәхетле,*
*Бәхетләрегез булсын гомерле.*
*Җирдә булган бөтен изгелекне*
*Бирсен Ходай Сезгә бу көнне.*
*Тормыш юлыгыз һәрчак балкып торсын,*
*Ягымлы, шат булсын күңелегез.*
*Озын гомер, бәхет-шатлык белән*
*Бер кайгысыз үтсен гомерегез.*
*Һәр көн Сезне котлап кояш чыксын,*
*Сезне назлап җилләр иссеннәр.*
*Яшәү матурлыгы, яме булып,*
*Көн артыннан көннәр үтсеннәр.*

**Матур теләкләр белән элеккеге укучыларыгыз Гөлфия Абәйдуллина, Нурия Тимербулатова, Нурия Сәляева, Зәкия Ахметова, Сәкинә Хаматова, Шамил Мусин, Җиһанша Абдуллин, Равил Тимушев, Тәүфыйк Байгузин, Расим Абушаев.**

Иске Кулаткы – Мурманск – Санкт-Петербург.



28 май - Чикне саклаучылар көне

# Тормышыннан канәгать ул

Мосеевка авылында гомер итүче ачык йөзле, шат күңелле, ярдәмчел, ихтирамлы Равил Дәүләтшович Кузахметовка ятимлек ачысын бик иртәли – 2 яшьлек чагыннан ук татырга туры килә. Аның әле дөньяны танып кына белә башлаган шушы чорында әтисе Дәүләтша Хәбибуллович вафат була. Әнисе Мөнәвәрә Әсвәновна ике баласын кочып, бер ялгызы тормыш йөген тарта. Мәктәптә техник хезмәткәр булып эшли, балаларына ныклы белем бирергә тырыша.

Равил Дәүләтшович мәктәптә 8 сыйныфны тәмамлап, беренче хезмәт чыныгуын колхозда ала. Ат җигеп, печән, салам, су ташый, кая кушсалар да баш тартмый. Кайда гына эшләмәсен, ул үзенең хезмәт сөючәнлеге белән хөрмәт казана.

Район үзәгенә йөреп, шоферлыкка таныклык ала. Яшь егетнең солдат булу теләге дә тормышка аша: 1961 елның ноябрендә Совет армиясенә хәрби хезмәт үтәргә китә. Аны Азәрбайҗанга, Линкорань шәһәренең 44 нче чикне саклаучы отрядына билгелиләр. Иң беренче хәрби әзерлек үткәрәләр. Хәрби осталыгына өйрәнү, чыныгу, туган илне сакларга ант бирү, техника серләренә өйрәнү – барысына да түземлек кирәк булган. Аның өстенә әнине, якыннарны, туган якны сагынулар… Техниканы ятарканга, аны төзек тотканга күрә, шофер һөнәре аңа җиңел бирелә. Туган илгә мәхәббәт, чик сагында җаваплы булырга, авырлыкларга түзәргә ярдәм итә. 2 ел дәвамында биредә хәрби хезмәт үткәч, Равил абыйны Төркиянең чик буена күчерәләр. Монда да авыл егете үзен уңай яктан гына күрсәтә. Тәртипле, намуслы, уяу, өлгер булганга, командование да аны хөрмәт итә. Хәрби хезмәтендәге уңышлары өчен ул "Бик яхшы чикне саклаучы" билгесенә ия була.



Ил каршында изге бурычын үтәгәч, туган якларына әйләнеп кайта, егетне "ике куллап" колхозга эшкә алалар. Озакламый авыл кызы Фәүзия Сабировна белән матур гына гаилә корып, 4 кызларын тәрбияләп үстерәләр, һәрберсенә ныклы белем биреп, тормышта үз юлларын табарга ярдәм итәләр. Фәүзия апа гомере буе фермада хезмәт итә. Ә инде Равил абый лаеклы ялга чыкканчы, 40 ел дәвамында шофер булып эшли. Карусыз хезмәте турында күп санлы Почет грамоталары, Рәхмәт хатлары сөйли. Бүгенге көнгә Равил абыйның кызлары: Римма, Лилия, Илмира, Рита үз гаиләләрен корып, әтиләренә оныклар бүләк иттеләр. Кызганычка каршы, Фәүзия апа моннан 14 ел элек гүр иясе булды. Өендә ялгыз гына гомер кичерсә дә, ялгыз түгел Равил Дәүләтшович. Балалары еш кайталар, әтиләренең хәлләрен белешәләр, ярдәм итәләр.

- Шушындый бәхетле тормышта яшәвемә бик шатланам. Бүгенге көндә илебезнең чын патриоты булу мөһим. Бөтен нәрсә дә үзеңнән тора, үзеңне нык тотарга, чыныгырга, белемгә, һөнәргә омтылырга кирәк. Укуны, спортны, хезмәтне ятарырга кирәк, - дип теләде ул яшь буынга.

Ачык йөзле, җор сүзле, җитез, беркайчан да зарлану белми, авыр минутларны җиңеллек белән үткәреп җибәрергә күнеккән Равил Дәүләтшович соклану хисләре уята. Тормышыннан канәгать ул, балаларына рәхмәтле.

Чикне саклаучылар көне уңаеннан без дә Равил Дәүләтшовичка ихлас теләкләребезне җиткерәбез. Исән-имин булып, бала-оныкларының мәхәббәтен, ихтирамын, игътибарын сизеп, озын-озак яшәргә язсын Сезгә.

**Әлфия ЯФАРОВА.**

# ТӘБРИКЛӘҮЛӘР КАБУЛ ИТЕГЕЗ!

**Мосеевка авылында гомер кичерүче Абдулхак Ибраһимович САЙФУЛЛИН 26 майда 85 яшьлек юбилеен билгеләде. Кадерле, сөекле әтиебез, яраткан бабакаебыз, хөрмәтле кодабыз!**

Сине ихлас күңелдән юбилеең белән тәбрик итәбез. Сиңа аяз күк йөзе, нык сәламәтлек, кояштай озын гомер, чиксез шатлыклар телибез. Сабыр холыклы, мәрхәмәтле, ярдәмчел, кадерледән-кадерле, олы йөрәкле булып кал. Ходай насыйп итсен сиңа алдагы көннәреңдә дә сәламәтлек белән гомер итәргә, якыннарыңның игелеген, хөрмәтен тоеп, безнең шатлыкларга сөенеп яшәргә язсын иде. Без сине чиксез яратабыз!



*Сиксән биш тапкыр язлар сиңа,*
*Бүләк итә гомер гөлләрен.*
*Бәхет белән үтсен гомерләрең,*
*Котлы булсын туган көннәрең.*

**Изге теләкләр белән улың Фәһим, кызларың Рәшидә, Роза, киленнәрең Сафия, Эльвира, кияүләрең Рәис, Камил, оныкларың Эльвир, Эльнар, Раил, Риналь, Руслан, Риналь, Илдар, Рафис, Радик, барча оныкчаларың һәм кода - кодагыйларың.**

Мосеевка – Карамалы – Тольятти - Иске Атлаш - Евлейка - Ташкент.

Районыбызда гомер кичерүче хезмәт ветераннары **Гөлҗиһан Сәлимҗановна Ахтәмова (Иске Кулаткы), Зәйтүнә Минһачевна Ибраһимова (Кирюшкино), Вера Васильевна Коновалова (Чуваш Кулаткы), Тәүхидә Усмановна Рәхимова (Карамалы), Флюра Шикуровна Хайрова (Яңа Терешка), Рәис Рызванович Шәрипов (Урта Терешка), Ринат Ахметович Шахутдинов (Иске Кулаткы), Расимә Абдулхаевна Ягудина (Иске Кулаткы)** 2017 елның июнь аенда үзләренең истәлекле 70 яшьлек юбилейларын билгеләп үтәләр.

**Кадерле хезмәт ветераннары, өлкән буын вәкилләре!**

Район ветераннар Советы Сезгә истәлекле юбилейларыгыз уңаеннан фидакарь хезмәтегез, ихтыяр көчегез, районыбызга булган ихлас мәхәббәтегез өчен рәхмәт һәм хөрмәт сүзләрен, котлауларын җиткерә! Сезгә чын күңелдән нык сәламәтлек, тынычлык, иминлек һәм бетмәс-төкәнмәс тормыш энергиясе телибез! Сезнең тормышта шатлыклы очрашулар күп булсын, туганнарыгыз һәм якыннарыгыз күңел җылысы белән шатландырып, Сезнең турында һәрвакыт кайгыртып, игътибар күрсәтеп яшәсен!

## Әбиләр һәм бәбиләр очрашты



Җәйнең беренче көне – балачак иленең иң матур бәйрәме. Шуңа да балалар бу көнне зур түземсезлек белән көтеп ала. Әлеге бәйрәм безгә, өлкәннәргә, һәр баланың яклауга, кайгыртуга мохтаҗ икәнен искәртеп тора. Чөнки үсеп килүче буын – ул безнең киләчәгебез, илебезнең киләчәге. Без алар хакына яшибез. Балаларыбызны мәрхәмәтле һәм кешелекле булырга өйрәтү – изге бурычыбыз. Шуны тормышка ашыру максаты белән Россия Пенсия фондының Иске Кулаткы идарәсе Пенсионерлар Союзы белән берлектә "Гөлчәчәк" һәм "Чишмә" балалар бакчалары нәниләре белән өлкән буын апалары очраштырдылар. Бу чара район Башлыгы Э.Ә. Ганеевның спонсорлык ярдәме белән тәмле ризыклар белән тулы өстәлләр артында үтте. Балалар әбиләренә багышлап, үзләренең җыр-моңга сәләтләрен күрсәттеләр, шигырьләр сөйләделәр, биюләр башкардылар. Бу очрашуга балаларны чакырып, алар өчен мөнә дигән очрашу-чара оештыру мактауга лаек. Буыннар очрашуы алар күңелендә озак сакла违ныр. Моның өчен Россия Пенсия фондының Иске Кулаткы идарәсе җитәкчесе Ш. С. Курамшинга, пенсионерлар Союзы рәисе Р.Я. Мусинага, балалар бакчалары җитәкчеләре, өлкән яшьтәге буын рәхмәтен белдерде. Пенсия Фонды идарәсенең хезмәтләре, киң күңеллеге, бирердәге уңайлыклар кунакларда җылы тәэсирләр калдырды.

**М. САНАТУЛЛИНА.**

## Карашыбызны Изге Болгарга юнәлтәбез



Идел буе Болгар дәүләте, Бөек Болгар... Үткәннәрне искә төшергәндә, халкыбыз тарихы сәхифәләрен актарганда, рухи һәм дини үзәкләребезгә карап сөенгәндә, һәркайсыбыз иң элек Болгарны күз алдына китерә.

Чынлап та, Болгар – дәүләтчелек традицияләрен төрки каһанлыклар, Бөек Болгар дәүләте заманнарыннан ук дәвам итүче иң күренекле җиребез, Урта Иделдәге иң беренче дәүләт.

Безнең Иске Кулаткы районы халкы өчен андый изге җиргә бару - хаҗга барганга тиң. Изге Болгар җире елдан-ел камилләшә, зурая, матурая бара. Шөкер Аллаһыбызга мөселманнарга югары гыйлем алу өчен академия дә төзелеп бетkән, ачылу дәрәҗәсендә тора.

Гади авыл хатын – кызларының шушы изге җиргә җитеп догалар кылып, намазлар укуы - олы бәхеткә ирешү ул. Анда чыгыш ясаучыларның һәр сүзен йотлыгып тыңладык һәм күз яшьләре аша шатландык. Динебезне тагын да куәтләндерергә, аңа тагын да күбрәк кешеләрне җәлеп итәргә мөмкинлекләр булдырырга сөйләделәр. Бик шатландык, канәгать булдык.

Безне бик уңай шартларда, алдан ук оештырып, исән – имин илтеп кайтарган өчен олы рәхмәтләребезне районыбыз Башлыгы Э.Ә. Ганеевка җиткерәсебез килә. Саратовтан уңай автобус җибәргән. Җитәкчебез, алып баручыбыз, юл буе һәркайсыбыз турында кайгыртып барган, анда да үзебезне берләштергән өчен Зәйтүнә хаҗия Абдюшевага да рәхмәтләребезне җиткерәбез. Юл буе догалар кылып, намазлар укып барганга күрә, Аллаһы ярдәме белән сәфәребез бик җиңел үтте. Кайткач та ачык йөз белән безне район администрациясе Башлыгының кеше потенциалын үстерү буенча урынбасары В.А. Деникаева каршы алды. Барчасына да олы рәхмәтләребезне белдерәсебез килә. Изге эшләр, изге гамәлләре Аллаһының рәхмәте өчен булсын. Бик күптән, 922 елда ата-бабаларыбыз тарафыннан татар халкының тарихи язмышын билгеләгән һәм мөселман цивилизациясе үсешенә зур йогынты ясаган үтә мөһим карар кабул ителгән. Унбер гасырга якын вакыт узса да, хәзер без янәдән карашыбызны рухыбызга үсеш биргән Борынгы Болгарга юнәлтәбез, Мәрхәмәт һәм Шәфкать иясе Аллаһыга мәдхияләребезне ирештерәбез, тәкъва хакимнәрнең гамәлләрен һәм зирәк дин әһелләренең вәгазьләрен хәтергә төшерәбез.

**Роза ӘХМӘТҖАНОВА.**
**Иске Мостяк авылы.**

## Җәй балалар өчен ял булсын иде



Балалар бакчасы - бала тормышындагы яңа һәм шул ук вакытта иң катлаулы этапларның берсе. Өйдән, әнидән аерылып, яңа дусларга, яңа кагыйдәләргә ияләнүе бала өчен дә, әниләр өчен дә бик катлаулы ул.

Хәер, балаларның күбесе балалар бакчасына беренче тапкыр килгәч, бар дөньясын, хәтта әнисен онытып, яңа уенчыклар белән уйный. Ләкин икенче көнгә яисә берничә көннән бала елый башлый, чөнки яңа үзгәрешләр барлыкка килә: көн тәртибе, яшьтәшләр белән аралашу, моңа кадәр таныш булмаган апаны тыңлау, аерым игътибарның кимәт кимүе һ.б. Болар һәр балада да була торган күренешләр. Шушы көннәрдә "Чишмә" балалар бакчасында әти-әниләр җыелышында булдык. Яхшы эмоцияләр белән сөенеп-шатланып кайттым. "Чишмә" балалар бакчасы мөдире – Галия Илдусовна Аблязова әти - әниләрне бакчадагы эш тәртибе, уставы, планнары, кагыйдәләре, торышы белән таныштырды. Әти -әниләрнең һәрбер сорауына җавап биреп, ул гына да түгел, очрашуга район больницасының врач – педиатры Н.Д. Фәйзуллин да, район администрациясенең балигъ булмаган балалар эше буенча комиссиясенең баш белгече В.Р. Байбикова да ата – аналар алдында чыгышлар ясадылар, сорауларына җаваплар бирделәр. Һәркайсының максаты – балаларның сәламәтлеген, иминлеген саклау, аларны начар юлга басудан тыю иде. Әлбәттә, әти – әниләр бакчага килгәч, тәрбиячеләре балаларның бирелә нинди казанышларга ирешкәннәрен күрсәтми калмыйлар. Кече төркемнән алып өлкәненә кадәр сәнгатьттә, җырга - биюдә ирешкән сәләтләрен күрсәттеләр. Баланың матур итеп җырлавын, я булмаса биюен карап тору - үзе бер сөенеч, җанга рәхәт иде. Исән – сау бала гына шулай үз төркемендә башкалар белән бертигез кылына ала. "Баланың сәламәтлеген, иминлеген саклау тулысынча диярлек ата – ана намусында, аларга, бигрәк тә җәйге чорда сак булырга, баланы күз уңыннан югалтмаска кирәк. Чөнки сабыйлар җәен урамда, су тирәсендә уйнарга яраталар. Ә ата – ананың бу чорда эше күп. Иң яхшысы балалар белән бергә булып, эшләрне дә башкарырга, уйнарга да бергәләп чыгарга кирәк", диделәр чыгыш ясаучы белгечләр. Бу җыелыш бик эчтәлекле һәм вакытлы булды. Балалар бакчасы мөдире Г.И. Аблязова барысын да тирәнтен уйлап эш иткән.





**Майзә МАСИЕВА.**

Мәктәп тормышы

# Фәнни-гамәли семинар нәтиҗәле үтте

Иске Кулаткы беренче номерлы урта мәктәбендә 2014 елда өлкә экспериментальь мәйданчыгы статусында инновацион процессларны үстерү программасы тормышка ашырыла башлады. Әлеге программада барлык педагогларыбыз да бик теләп катнаша. Өч ел эчендә үзебез укыткан фәннәр буенча зур тәҗрибә тупладык һәм башка мәгариф оешмалары белән дә бик теләп уртаклашабыз. Шулай ук предметара элемтәләрне ныгытуга, дәрестән тыш эшчәнлекне файдалы итеп үткәрүгә дә зур игътибар бирелә. Районыбызда булып үткән “Сәламәт яшәү рәвеше һәм бәхетле гаилә өчен” өлкә агитпоезды кысаларында безнең мәктәптә инновацион процессларны тормышка ашыру буенча “Төп мәктәп укучыларын социальләштерү чарасы буларак дәрестән тыш эшчәнлек вакытында предметара элемтәләр



һәм табигый – фәнни һәм технологик белем бирүне куллану” темасы астында муниципальара фәнни-гамәли семинар үтте. Семинарның эшендә Ульяновск шәһәреннән килгән кунаклар, район мәгариф идарәсе белгечләре, Иске Кулаткы, Радищево, Павловка һәм Новоспасск районнарыннан килгән мәктәп директорлары һәм укытучылар (барлыгы 45 кеше) катнашты. Килгән кунакларны мәктәп директоры Г. В. Бәширова каршы алды. Семинар тантаналы ачу церемониясеннән башланды, мәктәп хоры башкаруында Россия гимны яңгырады, актлар залында кунаклар өчен чәй өстәлләре әзерләнде. И. Н. Ульянов исемендәге Ульяновск дәүләт педагогия университетының информацион технологияләр кафедрасы доценты, биология фәннәре кандидаты Елена Владимировна Спирина һәм Ульяновск өлкәсенең мәгариф һәм фән Министрлыгының баш белгече Елена Николаевна Папуша семинарда катнашучыларга сәламнәрен җиткерделәр һәм үзләренең чыгышларында мәктәбебезнең инновацион процессларны үстерү юнәлешендә башкарылган эшләренә югары бәя бирделәр. Шулай ук Иске Кулаткы районы мәгариф идарәсе җитәкчесе Ф. З. Зайнетдинова һәм мәктәптә фәнни-методик эшчәнлеге җитәкчесе, югары категорияле биология фәне укытучысы Р. Р. Аделова да төрле темалар буенча чыгышлар ясадылар. 2017 елның 3 мартында Татарстан Республикасының Яшел Үзән шәһәрендә Каюм Насыйри исемендәге XV Халыкара фәнни – тикшеренү конференциясендә җиңү яулап кайткан укучылар Марсель Юмангулов һәм Ильяс Курамшин фәнни - тикшеренү эшләренең презентацияләрен тәкъдим иттеләр. Аннары барлык катнашучылар да семинарның гамәли өлешенә чакырылды. Мәктәп укытучылары төрле дисциплиналар буенча дәресләр күрсәттеләр. Семинарның йомгаклау өлешендә түгәрәк өстәлләр оештырылды. Соңыннан педагоглар үз фикерләре белән уртаклаштылар, тәкъдимнәрен әйттеләр. Барлык катнашучыларга да сертификатлар бирелде һәм рәхмәт хатлары тапшырылды. Укытучылар бик күп файдалы мәгълүмат белән уртаклашып, мавыктыргыч дәресләр күрсәткән мәктәп коллективына олы рәхмәт сүзләрен җиткерделәр һәм уңышлар теләделәр.

**Гөлшат УСМАНОВА,**
**Иске Кулаткы беренче номерлы урта мәктәбенең тәрбия эшләре буенча директор урынбасары.**

## Ветераннарны котлыйбыз!

**2017 елның июнь аенда районыбызда гомер кичерүче Бөек Ватан сугышы ветераны Исхак Мөбинович Алиев (Мосеевка) истәлекле туган көнен билгели.**

**Хөрмәтле ветеран!**

Район ветераннар Советы Сезне истәлекле туган көнегез белән тәбрик итә. Илебез азатлыгы өчен көрәштә күрсәткән батырлыгыгыз алдында баш иеп, Бөек җиңүне яулап кайтканыгыз өчен Сезгә олы рәхмәт белдерәбез. Исәнлек-саулык, җан тынычлыгы, шатлыклы көннәр телибез. Якыннарыгызның игелеген күреп, озын гомер итегез!

Район ветераннар Советы Бөек Ватан сугышының соңгы чакырылыш солдаты **Идрис Туктарович Аввәсов (Югары Терешка),** тыл хезмәтчәннәре **Тәнзилә Алиевна Деникаева (Вязовый Гай), Вәсимә Халиулловна Алюшева (Иске Кулаткы), Зәкәрья Мохаррәмович Измайлов (Урта Терешка), Акилә Сафовна Хамзина (Урта Терешка), Рәгиб Идрисович Абдюшев (Иске Атлаш), Нәфисә Исхаковна Яфарова (Иске Атлаш), Фәһимә Мингазетдиновна Сыраҗетдинова (Иске Атлаш), Зәйтүнә Хәсәновна Хакимова (Иске Мостяк), Гөлемсылу Халиловна Усманова (Иске Кулаткы), Вера Ивановна Самайкина (Чуваш Кулаткы), Аҗирә Хәсәновна Сәйфуллина (Яңа Терешка), Рауза Якубовна Исхакова (Иске Кулаткы),Сәимә Борһановна Курмашеваны ( Яңа Кулаткы)** гомер бәйрәмнәре белән котлый, Бөек Ватан сугышы елларында туган балалар статусын йөртүче һәм июнь аенда үзләренең олы юбилейларын билгеләп үтүче **Рәисә Низамовна Богданова (Иске Кулаткы), Тәлгать Сахабович Гизетдинов (Иске Мостяк), Мөнзилә Абдрахмановна Егорова (Зирекле), Мәрьям Исмаиловна Кадермәтова (Иске Кулаткы), Сания Идрисовна Караева (Иске Кулаткы), Гөлҗиһан Батырхановна Курмакаева (Яңа Зеленай), Рәхимә Исхаковна Камалова (Яңа Зимница), Җәфәр Абдулхаевич Нагаев (Яңа Зеленай), Хөррия Яхьевна Нагаева (Яңа Зеленай), Адельша Биляловичс Сәйфетдинов (Иске Атлаш), Рәисә Садыковна Салихова (Вязовый Гай), Мөнирә Салихҗановна Тимендарова (Бахтеевка), Якуб Абубәкәрович Хәбибуллин (Иске Атлаш), Мәрьям Хөсәиновна Шаяхметованы (Иске Зеленай)** чын күңелдән олы бәйрәмнәре белән тәбрик итә.

**Хөрмәтле юбилярлар!**

Дәһшәтле сугыш елларында дөньяга килеп, шатлыклы, борчу-хәсрәтсез, михнәтсез балачактан мәхрүм булдыгыз. Әмма сугыштан соңгы елларында илебезне торгызуда, халкыбыз, киләчәк буын рәхәт тормышта яшәсен өчен, гомер барышында күп тырыштыгыз, үзегездән өлеш керттегез. Сезгә саулык-исәнлек, гаилә бәхете, җан тынычлыгы телибез. Киләчәк тормышыгызда да саулыкта, муллыкта, якыннарыгызның игътибарын, җылысын тоеп яшәргә насыйп булсын.

*Сезнең тормыш юлы – матур тарих,*
*Күпләр өчен үрнәк булырлык.*
*Рәхмәт, дибез, Сезгә чын йөрәктән*
*Сезнең гомер – безнең горурлык.*

Сугыш урлаган балачак

# Әби-бабаларыбыз белән горурланыйк!

Мин әти – әнием белән Мәскәү шәһәрендә яшәсәм дә, җәйге ялларымны Иске Мостяк авылында яраткан әбием Рәйсә Шәүкәтовна һәм бабаем Ришат Якубович Динюшевлар янында үткәрәм. Алар икесе дә, сугыш елы балалары буларак, миңа авыр балачаклары турында бик еш искә алып сөйлиләр һәм тыныч тормышның кадерен белеп яшәргә өйрәтәләр. Ә бит без чыннан да, XXI гасыр балалары, бәхетле тормышта яшибез. Җылы, иркен һәм якты мәктәпләрдә белем алабыз. Төрле заманча техника белән идарә итәбез, компьютер аша дөньяның төрле почмакларында яшәүче дусларыбыз белән аралашабыз, төрле программалар ярдәмендә чит телләрне үзләштерәбез. Илебез буенча һәм чит илләргә сәяхәт кылабыз, җәй көннәрендә лагерьларда ял итәбез, яратып спорт белән шөгыльләнәбез. Бәхетле балачагыбыз өчен барлык мөмкинлекләр һәм шартлар булдырылган. Ә бит шундый якты һәм рәхәт тормышны булдыру өчен безнең әби-бабаларыбызга бик күп михнәтләр һәм



авырлыклар кичерергә туры килгән. Бөек Ватан сугышы елларында ачлык-ялангачлыктан һәм юклыктан интексәләр, сугыштан соңгы елларда илебезне торгызу өчен көнне-төнгә ялгап эшләгәннәр. Сугыш елларында аларга нибары 3 – 10 яшь булган. Бүген без аларны «сугыш елы балалары» дип йөртәбез. Әби-бабаларыбыз кулларына корал алып дошманга каршы сугышмасалар да, күңелле җырлар, шатлыклы көлүләр тыңлау урынына бомба шартлауларын, әниләренең җылаганнарын тыңлап, югалту ачылыгын татып үскәннәр. Авылда кызлар, картлар, балалар колхоз эшенә җигелеп тартканнар.Көне-төне эшләсәләр дә, ашарларына җитмәгән.Икмәкне фронтка озатырга кирәк булган. Җәй көннәрендә балтырган, кузгалак, ачы какы, төче какы, кычыткан, чөгендер яфрагы – барысы да ризыкка әйләнгән. Бу авыр елларда авыл язмышы ил язмышына кушылган. Шундый авыр шартларда да, балалар якты киләчәккә ышанып яшәгәннәр. Ирләре, уллары, туганнары яу кырында батырлыклар күрсәткәндә тылдагы хатын-кызларыбыз, яшүсмерләр үзләрен аямыйча кырларда, заводларда һәм фабрикаларда эшләгәннәр.

Без, бүгенге балалар, - бәхетле буын. Чөнки безгә сугыш дигән явызлыкны күрергә туры килмәде һәм килмәсен дә. Шуңа да без бәхетле! Ләкин без сугышның нинди яман чир икәнлеген белергә, аны тудырырга тырышучыларга киртә булырга тиешбез. Ничә йөз еллар үтсә дә, фашизм алып килгән бәхетсезлекләрне, кайгы - хәсрәтләрне тарих битләреннән, әдипләребез язып калдырган әсәрләрдән укып төшенергә, әби-бабаларыбызның дошманга каршы көрәштә күрсәткән данын сакларга, җир йөзенә яшәү өчен туган башка кешеләргә карата намуслы, олы йөрәкле, кече күңелле булып калырга тиешбез. Әби – бабаларыбызның данлыклы гомер юллары белән горурланыйк һәм хөрмәт итеп яшик!

**Илдар САЛИХОВ,**
**VII сыйныф укучысы.**

Рәхмәт хаты

# Ярдәм кулы суздылар

Кол Шәриф мәчетенең мәһабәтлелегенә, затлылыгына, гүзәллегенә сокланып, сөенеп йөргәндә, кинәттән башым әйләнеп китеп, хәлем начарайды. Ярый, әле минем хәлсезлегемне сизеп, янәшәмдә булучы дин кардәшләрем мине тотып калып, баскычлардан егылып төшүдән сакладылар. “Сафия” мәчете имамы Ринат Бәширов, Яңа Яндука авылы имамы Рафик Алтынбаев төшенкелеккә бирешмичә, тиз арада ярдәм итәргә ашыктылар. Даруларымны биреп, мине тынычландырып, хәлем уңайлануга кадәр янымда тордылар. Аларның тиз арада ярдәм итүләре, җылы сүзләре, яхшы мөгамәләләре миңа бик булышты.

Мәрхәмәтле, игътибарлы, кайгыртучан, ярдәмчел дин кардәшләремә олы рәхмәтемне һәм тирән ихтирамымны белдереп, ныклы сәламәтлек, җан тынычлыгы, җаваплы хезмәтләрендә уңышлар, зур шатлыклар теләп калам.

**Нурали САФАРОВ,**
**Иске Атлаш авылы мәчете имамы.**

### БЕРГӘЛӘП УКЫЙБЫЗ

# САГЫНЫРСЫҢ МИН БУЛМАМ

## *Повесть*

**Зифа Кадырова**



Тагын җомга җитте. Вокзалга алданрак килде, энесе дә килеп җитте.

- Нәрсә, абый, курчагың кайда бүген?Әллә кертеп утыртырга да өлгердеңме? - дип сорап куйды. Булат дәшмәде.

Алар Сөмбелләр авылына кайтучы автобусны икәүләшеп күзәтә башладылар, тик кыз килмәде дә, күренмәде дә. Байрасның күңеле кителеп калды, ул аның елмаеп, кул болгап озатып калуын ярата, хәтта абыйсыннан көнләшә иде. Кирәк бит, аз гына соңга калды, ул йолдызга абыйсы үрелгән, ә абыйга аркылы төшеп булмый; чит кеше булса, әллә кайчан төбе-тамыры белән йолкып аткан булыр иде. Юк шул, ярамый, абый бит...

Сөмбел Булат яныннан ничек кузгалып киткәнен, кая таба барганын да аңламады. Берничә минут, берничә сүз йөрәкне телгәләп учка тоттырды. Аның бөтен җире таш булып катты.

Урамда салкын көз, урыны-урыны белән бозлавык, салкын ачы җил, тик ул аларны сизмәде, барды да барды, шәһәр буйлап йөрде дә йөрде... Беркичтә бөтен дөнья үзгәрде, ничаклы вакыйга булды, ул йөкле, бала көтә, ә ул бала... Ул беркемгә дә кирәкми, аны яратмаганнар да... Менә хәзер беркемгә дә кирәкмәгән ике бәхетсез җан салкын көздә буш шәһәр урамында адашып йөри. Әле кичә генә барысы да башкача иде, ул мәхәббәте белән бик бәхетле, дөнья матур, якты, берниндиборчу-кайгысы юк иде. Авылына кайтса, өе, әнисе шатланып каршы ала, монда килсә эше, сөеклесе көтеп тора иде. Ә хәзер? Ә хәзер әнисе кайгысыннан үләр, аны өйгә дә кертмәс, хурлыгы ни тора бит... Ирсез бала тапкан, тегенең уйнаштан туган баласы, дип, бармак төртеп сөйләячәкләр...

Ул шулай урам буйлап барды да барды, шәһәр читенә ничек килеп җиткәнен дә, тимер юл буйлап баруын да сизмәде, уйлары аны еракка-ракк алып киткән иде шул... Өстенә каяндыр якты ут якынлаша башлады, ул аңа каршы китте, ник каршы барганын үзе аңламады. Ут туктады, тик сүнмәде, каршысында зур бер абый пәйда булды.

- Нишлисең монда? Шушы яшеңнән яшәүдән туйдыңмы? Бар, өеңә кайт, - дип орыша - орыша, Сөмбелне читкә чыгарып бастырды. - Әнә шәһәргә кайта торган юл, ә бу юл комбинатка бара. Бәхетең, пассажирлар йөртүче булса, таптап та киткән булыр иде. Син бит бала гына, син үлсәң, әти-әниең кайгыдан үләчәк, ә мине кеше таптаган өчен төрмәгә утыртырлар иде, минем балаларымны кем үстерер иде? Бар, өшеп беткәнсең бит. Әллә телсез инде мескен, - диде дә борылып китеп барды.

Сөмбел кая барырга белмичә туктап калды, шәһәргә кайтыйм дип бара торгач, үзе эшли торган балалар бакчасына килеп төртелде. Ишек шакыганда, аның инде теше-тешкә тими иде. Каравылда торучы ялгыз карчык аны күргәч:

- Сөмбел, нәрсә булды? Нишләп йөрисең? Нишләттеләр сине? - дип кочаклап алды. - Хәзер кайнар чәй эчерәм, кил монда, сал киемнәреңне, - дип, ул аны тартып-йолкып чишендерде дә җылы одеялга төреп утыртты. - Хәзер чәй китерәм, җылынырсың.

Сөмбел шушы балалар бакчасында няня булып эшли, балаларны да, эшен дә бик ярата. Унынчы сыйныфны бетергәч, укырга кермәде, монда эшкә урнашты. Бу әбине баба Вера дип йөртәләр, ул төнге каравылда гына тора. Ул йөгерә-йөгерә кайнар чәй китерде.

- Мә, кояшым, эч. Ни булды сиңа, кем рәнҗетте, йөзеңдә кан әсәре калмаган бит. Син ела, оялма, карт булсам да, мин барысын аңлыйм. Болай катарга ярамый, йөрәгең күтәрмәс, еларга кирәк, еларга. Син салкын тидергәнсең, ахры, ят әле, - сөйли-сөйли Сөмбелне әллә ничә одеял белән төрде. - Мин аңлыйм, дело молодое, бар нәрсәгә мәхәббәт гаепле, бер син генә түгел, бөтен кеше кичерә аны. Син эчеңне бушат, сөйлә, ела, көрәш, болай ярамый, кояшым. Мин күпне күрдем, мин сугышны үттем, сугышта әлләниләр күрергә туры килде. Кеше җиңә алмаган кайгы-хәсрәт юк, кояшым, Ходай кешегә күтәрә алмаслык кайгы бирми. Ике иңбашында ике фәрештәң утыра, алар сиңа бар авырлыкны күтәрешә, бары вакыт, бары сабырлык кирәк. Сугыш белән ачлыктан кала барысына да түзәргә була. Яшәргә кирәк, кояшым, яшәргә кирәк. Вера әби бик озак Сөмбелнең башыннан сыйпап утырды.

Бу төндә кызның маңгаена беренче озын сыр сузылып ятты.

Баба Вера иртән кызның температурасын үлчәгәч, кырыкка якын икәнен күреп, курка калды, ашыгыч ярдәм чакыртты. Сөмбелне шунда ук алып киттеләр, ул аңында түгел иде инде.

Сөмбел өч көннән соң гына аңына килеп, кеше танырлык булды. Яшәү белән үлем арасында тартышу аның барлык көчен, йөзендәге нурын алды. Ул аңына килгәндә, янында һаман шул Вера әби утыра иде.

-Кояшым, көн-төн Ходайдан синең терелүеңне сорадым. Болай булгач, барысы да артта калды, яшәрсең, Алла боерса. Син бит өч көн аңсыз ятасың, - дип, үзе сөйләнде, үзе аның кара янып ярылып беткән иреннәрен чылатты.

Шунда ук табиблар кереп җитте. Олы яшьтәгесе бар яклап тыңлап карагач:

- Үскәнем, сез бик нык салкын тидергәнсез. Үзегезнең йөкле икәнегезне беләидегезме, анализлар шулай күрсәтә. Сезгә бик озак дәваланырга туры киләчәк, бөтен ышаныч үзегездә. Без сезгә булышырбыз. Туачак сабыегыз турында да онытмагыз. Барлык даруларны эчәргә, бик яхшылап ашарга һәм мөмкин кадәр тизрәк депрессиядән чыгарга кирәк. Әбиең, сине саклап, өч көн ашамый - эчми монда утыра, - дип, капельница куйды.

Баба Вера, чиста киемнәр дә алып ки¬лермен, дип кайтып китте.

Сөмбелне аерым палатада тагын бер атна яткырдылар да аннары гомуми палатага күчерделәр. Вера әбисе ашарга китереп, аның хәлен белеп торды.

- Баба Вера, әни белсә, мине өйгә кертмәячәк, мин дә, бала да беркемгә дә кирәкми. Минем барыр урыным да юк.

- Син башта терел, аннары сөйләшербез. Мин бит берьялгызым яшим, миңа кайтырсың, икәү күңеллерәк тә булыр. Кайгырма, кояшым. Син миңа Верочка дип дәш, алай мин үземне яшьрәк хис итәм.

- Ярар. Верочка, сиңа бер үтенечем бар. Безнең авылга кайтып килмәссеңме икән, әниләр мине югалткандыр инде, мин бит атна саен кайта идем. Бала турында берни дә әйтмә, кирәкми, үтенеп сорыйм.

- Ярый, кояшым, ярый...

Әнисе икенче көнне үк килеп җитте, кызын шундый хәлдә күреп телсез калды, беләгендә капельница, яргаланып беткән иреннәр... Верочка аны тыныч-ландырырга тырышты:

- Сез борчылмагыз, аның үпкәсенә бик нык салкын тигән. Тиздән терелер, яшь организм үзе көрәшә ул, диләр врачлар. Барысы да яхшы булыр, еламагыз.

- Мин хәзер киләм, - дип чыгып китте.

Үзе тиз генә докторлар җыела торган бүлмәгә кереп, Сөмбелне дәвалаучы табиб Власовны тапты.

- Гафу итегез, доктор, Сөмбелнең әнисе килде. Бик елый, кызын шундый хәлдә күреп, бик курыкты. Сез берүк аның авырлы икәнен әйтә күрмәгез инде.

- Яхшы, әйтмәм, борчылмагыз.

- Рәхмәт, доктор, рәхмәт.

Доктор да Сөмбелнең әнисен иплән кенә тынычландырып кайтарып җибәрде.

Сөмбелнең хәле шәптән түгел, ул төшенкелеккә бирелеп, катлаулы депрессия кичерә. Ә дөньядан ваз кичкән кешене дәвалау иләк белән су ташу гы¬на. Аны бу хәлдән чыгару өчен ныклы таяныч булырлык якын кеше, мәхәббәт, яклау, аңлау кирәк...

Ике атна үтте. Сөмбел бер ноктага карап ятуын белде, беркем белән сөйләшмәде. Марҗа әбисе аның янында бөтерелде дә бөтерелде. Җитмәсә, көчле токсикоз башланды. Ул хәзер бик ябыкты, хәлсезләнде.

Токсикозның көчле булуы бер яктан докторны куандыра, чөнки бу - карындагы баланың үсәргә, яшәргә тырышуын күрсәтүче билге иде. Ходай шулай язгандыр, алар шушы авыр хәлне җиңеп чыга алса, бер-берсенә сөенеп туймаячак әле. Ана булгач, ул барысын да онытачак, бәлки үзен шушы газапка салган кешесен дә кичерер. Доктор кызга бик озак карап торды. Әллә бик ябыгудан, әллә эчтән яндырган хәсрәттән Сөмбелнең ирен читендә ике кечкенә сыр барлыкка килгән иде.

Тагын җомга җитте, тагын яшьләр шау-гөр килеп, вокзалга җыелды. Октябрь бәйрәме якынлашкан чак иде, халык вокзалга агылды да агылды. Байрас, алдан килеп, абыйсы белән икесенә билет алды, бер яхшылык эшлим әле дип, абыйсының курчагына да билет алырга уйлады. Сөмбелне ул теге атнада күрмәде, аның көләч күзләрен, ничек шатланасын күз алдына китереп, үзалдына елмая - елмая, көчхәл белән чиратны ерып чыкты да абыйсын эзли башлады. Абыйсының тимер юл кассасы янында торуын күргәч, аптырап янына килде.

- Нишләп торасың монда? Мин инде сиңа да, курчагыңа да билет алдым. Үзе кайда соң әле?

- Энем, мин авылга кайтмыйм, Златоустка кунакка китәм. Әниләргә әйтерсең, югалтмасыннар.

- Ә Сөмбел?

- Белмим, минем инде аны ике атна күргәнем юк, бүлмәсенә кайтмый, кая йөридер. Дөресен әйткәндә, мин аның белән араны өздем. Ярый, бар, соңга каласың, очратсаң, билетыңны бир.

Байрас урамга чыкты, «Байрамгул» автобусы янына килеп, Сөмбелне эзли башлады, тик ул халык арасында күренмәде.

- Бәрәкалла, әллә син дә безнең авылга кайтасыңмы? Билетка якын барырлык түгел, кырмыска оясы кузгалган диярсең. Тукта әле, Байрас, нишләп торасың монда, кемне эзлисең? Әллә син дә безнең авыл кызын эләктердеңме?

- Мансур, мин Сөмбелгә билет алган идем, нишләптер күренми. Белмисеңме,кайта микән?

- Слушай, брат, ике атна инде юкка чыкканына, бүлмәдәш кызлары да берни белми, абыеңнан сора. Ачуым да бер килмәгәе, ни үзенә, ни кешегә... Мин бит аңа каян хат килгәнен, кая чапканын беләм, ә бу җүләр сабый аңа ышана. Хатын-кыз җүләр бит ул. Белмим, теге атнада кайтмады шикелле, клубка чыкмады.

Байрас эндәшми генә билетын Мансурга сузды:

- Мә алайса. Син белеш әле, бер-бер хәл булмасын тагын.

-Ярый, клубка чыгар әле, белешермен. Билет өчен рәхмәт.

Алар икесе ике автобуска утырып кайтып китте.

Өйгә кайтып керүгә, әтисе каршы чыкты.

- Бәй, улым, Булат абыең кайда?

- Китте.

- Кая китте?

- Күрше авылга, әй, Златоустка. Бәйрәмгә кайтмыйм, җиңгәң янына барам, диде.

Ярар, алайса, өйләнә башласагыз да ярый, озаклямый сугым суябыз, берсен сатарбыз, берсенә туй ясарга булыр.

- Ясарсыз, ясарсыз, - дисә дә, «Менә җиңгинең берсе кая югалды икән? Әллә соң берәр хәл булды микән?» - дигән уйлар Байрасның башыннан чыкмады.

Алар кичке ашка утыруга, дөньяның тоткасы, Ходайның кашка тәкәсе - Әлфис кайтып керде. Битләре кызарган, борын асты ялтырап тора, күзләре ут чәчә. Урамда кар ява, ахрысы, беренче кар.

- Бу вакытка кадәр нишләп йөрисең, маңка капчыгы, төн бит, әллә кызлар озата башладың инде? - дип, абыйсы үрти башлаган иде, Әлфис кычкырып көлеп җибәрде.

- Абый, абый, Рәмилләргә теге син озаткан кунак кызы тагын кайткан. - Әлфис өстен сала-сала үзенекен сөйли башлады. - Рәмил әйтә, теге атнада синең Байрас абыең безгә кайткан кунак кызын озаткан булган, төнлә апа белән чырык-чырык сөйләшеп яттылар, тыңлап яттым, ди. Теге апа әйтә, ди, Байрас капкага китереп терәде, үләм диеп торам, ул шундый шәп үбешә, миңа ошады, киләсе атнага тагын кайтам дип әйтте, ди. Әнә, кайтып та җиткән, сине көтеп йөри.

Байрас бер генә сикерде, тагын әллә ниләр ычкындырмасын дип, энесен күз ачып йомганчы эләктереп, олы якка кереп югалды.

- Син ни сөйлисең, әниләр алдында, бытбылдык? Иманыңны укытам бит.

- Рәмил бит шулай ди.

- Дисә соң, син бит егет кеше. Андый сүзләрне әни белән әти алдында сөйләмиләр инде. Уф, пычаксыз суйдың, хәзер ничек чыгып күреним? Бирермен берне җилкә тамырыңа. Алып кайтырмын мин сиңа икенче юлы сагыз.

Абыйсы тузынды да тузынды:

- Үсеп җитәрсең әле, мин дә сине шулай әниләр алдында хур итәрмен.

- Йөрдем, ди, кеше капка төбендә кызлар авызы ялап, - диде дә абыйсы эләктергәнче Әлфис чыгып та йөгерде.

- Ну, малай, эләктерсәмме?!

Байрас әниләре янына бүтән чыгып тормады, тиз-тиз генә киенде дә клубка чыгып тайды. Юл буе «чыбыксыз радио» дип энесен ачуланып барды.

Әнисе белән әтисе тавышсыз гына, күз яшьләре чыкканчы көлделәр. Әтисе төпчек улына иплән кенә:

- Улым, алай ярамый, андый сүзләрне колакка гына әйтәләр, син бит ир кеше, бүтән алай итмә, яме, - дип аңлатты.

- Ярар, әйтмәм, болай да муенны сындыра язды, - дип, Әлфис тагын кычкырып көләргә тотынды, аңа әтисе белән әнисе дә кушылды.

- Нәрсәдән көләсең, улым?

- Иртәгә Рәмил тагын сөйләр әле, классно, - диде дә сүзен әйтеп бетерми авызын япты. - Бүтән берни әйтмим, ашыйм да ятам, иртәгә кар күп итеп яуса, тау шуарга барабыз. Их, шәп булачак.

Әтисе төпчегенә карап елмайды, менә кемгә рәхәт ул дөньяда: Әлфис белән Мырабикәгә.

Байрас клубка килеп кергәндә, яшьләр җыелган, клуб шыгрым тулы иде. «Бүген дә кызлар озата барсам, иртәгә тагын нинди сүзләр ишетермен икән», - дип, башка егетләр янына почмакка басып, кунак кызларын күзли башлады. Егетләр белән күрешкән арада янына классташы Римма килеп басты, алар ерак кына туган да.

- Исәнме, Байрас, кунак кызларын күзлисеңме?

- Миңа кем дә ярый, күңелем киң, - дип көлде Байрас. Көлгәндә, аның ак тип-тигез тешләре ялтырый, ияк очлары чокыраеп китә, алар абыйсы белән бик охшашлар.

Римма аңа сокланып карады, бу асыл егет бик күпләрнең башын әйләндерә, ләкин яратып йөргән кешесе генә юк.

- Абыең никтер бер дә күренми, аның белән ныклап сөйләшәсе сүзем бар.

Клубка да чыкмый, әллә кайтмыймы?

- Өйләнергә җыена, бик кирәкле сүз булса, үземә генә сөйлә.

- Кемгә өйләнә, теге Байрамгул кызынамы? Ул бит шуның белән йөри.

- Юк, ул түгел. Әллә кайда, Златоустта аның кызы. Әле дә аның янына китте.

Бу җавапны ишеткәч, Римма гаҗәпләнеп Байраска карады.

- Ник миңа алай карыйсың? Курыкма, мин өйләнмим әле.

- Ә Сөмбел ничек?

- Белмим, анысы әллә кая китеп югалган, ди, абый үзе дә белми.

Римма бераз уйланып торды да:

- Әйдә, урамга чыгыйк әле, монда кеше күп, сөйләшеп булмас, - дип, Байрасны урамга тартты.

- Йә, нәрсә бар, сөйлә.

- Беләсеңме, Байрас, мин бүген клубка абыең белән сөйләшер өчен генә чыккан идем, эшләр болай булгач, сиңа сөйлим инде. Син бит минем кайда эшләгәнне беләсең, өстәвенә, реанимация бүлегендә дә эшлим; аннары, без бит ерак булса да туганнар. Булат абый үз кеше дигәндәй...

- Йә, сузма инде, анда кунак кызларын бүлешеп бетерәләр, мин һаман монда.

- Кыскасы, шул, абыеңа әйт, Сөмбел бездә ике атна инде авыр хәлдә ята,баштагы өч көндә бөтенләй аңсыз ятты. Комадан чыга алмас, үләр, дигән идек, комадан чыкты, ләкин беркем белән сөйләшми, бер ноктага карап тик ята. Ике атна бер якка да үзгәреш юк. Күрсәң,шундый кызганыч ул.

- Тукта, ни сөйлисең син, ни булган аңа? Берни аңламыйм. Кайда? Нишләгән?

- Белмим, безгә аны аңсыз, температурасы кырык килеш китерделәр. Әллә урамда бик озак йөргән, әллә егылып яткан, анысын белмим, бик каты сал¬кын тигән аңа. Врачлар, нәрсәдәндер бик каты тетрәнү кичергән, организмы көрәшә алмый, ди. Хәзер ул төшенкелеккә бирелгән.

Римма, башкасын әйтергәме дип бераз уйланып торды да, ни булса, шул булыр, үз кылганнары өчен үзләре җавап бирсеннәр дигәндәй, сүзен дәвам итте:

- Иң начары шул: ул авырлы, әгәр үлә калса, берьюлы ике гомер киселәчәк. Абыең өйләнгәнче уйласын. Бу гөнаһ белән ничек яшәр, ул бит аны бер ел курчак урынына җитәкләп йөрде, әнә хәзер барып карасын, таныр микән... Өйләнә икән, өйләнсен, җир йотар үзен, кабахәт җан. Менә шул... Римма, башка әйтер сүзем юк дигәндәй, кырт кына борылды да клубка кереп тормыйча кайтып китте.

Байрасның башына күсәк белән суккандай булды, ишеткәннәрен рәткә салып аңларга тырышты. Башка сыймас хәл бу: Сөмбелне харап иткән бит абыйсы! Ул, үз уйларына чумып, урам уртасында бераз басып торгач, әкрен генә кайту ягына атлады. Кунак кызларын озату түгел, үзенең кайда икәнлеген дә онытты шикелле.

Урамда кар ява, кыш җитә. Кар бөртекләре яшь егетнең битенә куна да эреп агып төшә, әллә кар, әллә күз яшьләре... Сыкрап-сыкрап йөрәге авыртты. Аның әле моңа кадәр кызлар өчен йөрәге әрнегәне юк иде: үпте, кочты, җилгә очты. Менә хәзер әллә ни булды, әллә бер кичтә олыгайды инде, үзен бернигә яраксыз итеп тойды.

Өйләренә кайтты. Әкрен генә кереп ятты, күзенә йокы да кермәде, бу хәлдән чыгу җаен да тапмады. Таң алдыннан гына йоклап китә алды. Ул уянганда, якты иде инде. Бәйрәм көн булгач, аерым эш тә юк. Ул, торып чәй эчкәч, авылның икенче очына, Риммаларга китте. Римманы урамга чакырып чыгарды.

- Сөмбел янына ничек керергә була? Мин аның фамилиясен дә белмим.

**(Дәвамы бар).**

# ТӘБРИКЛӘҮЛӘР КАБУЛ ИТЕГЕЗ!

**Усть Кулаткы авылында гомер итүче Факия Абдулкадировна АБӘЙДУЛЛИНАГА 30 майда 90 яшь тулды.**

Гаиләбезнең якты кояшы – газиз әниебез, яраткан әбекәебез, сөекле апабыз! Кадерлебез – син безнең таянычыбыз, ышанычыбыз, киңәшчебез, яшәү өлгебез. Сабыр сандыгының ачкычын гомер буе саклап яшәп, төпле акыллы киңәшләрең белән туганнарыңа ярдәм кулы сузасың, ышанычлы таяныч була беләсең, безгә – балаларыңа яшәү үрнәге күрсәтәсең. Без шатлык-сөенечләребез белән уртаклашырга да, борчу-мәшәкатьләребезне бүлешергә дә синең яныңа ашыгабыз. Авырлыкларны зур сабырлык белән җиңәргә, тормышта сынмаска-сыгылмаска, кешеләрне һәм тормышны яратырга син өйрәттең безне, кадерлебез. Син – гаиләбезнең алыштыргысыз яме һәм нуры. Киләчәктә дә мәңге сүнмәс кояшыбыз булып кал!

*Һәр көн сине котлап кояш чыксын,*
*Сине назлап җилләр иссеннәр.*
*Яшәү матурлыгы, яме булып*
*Көн артыннан көннәр үтсеннәр.*
*Күңел күгең һәрчак аяз булсын,*
*Читләп үтсен сагыш-борчулар.*
*Ныклы сәламәтлек юлдаш булсын,*
*Аннан кадерлерәк нәрсә бар.*
*Туган көнең - юбилеең белән*
*Чын күңелдән сине котлыйбыз.*
*Сәламәтлек, шатлык-куанычлар,*
*Күңел тынычлыгы телибез.*
*Юлларыңа ак бәхетләр ясусын,*
*Шатлык балкып торсын йөзеңдә.*
*Кайгы-хәсрәт баш очыннан узсын —*
*Шул теләкләр бездән үзеңә.*



**Изге теләкләр белән кызларың Өркия, Нурия-Фәрит, Роза-Фәрит, Равилә-Рафаэль, улың Иршат-Светлана, барчасы да гаиләләре белән, 7 оныгың, 6 оныкчаң, сеңелең Алия, тормыш иптәше Зыят Салиховлар.**

Усть Кулаткы – Мурманск – Мәскәү – Ульяновск – Хвалынск – Саратов.

**Югары Терешка авылында гомер итүче Идрис Туктарович АВВӘСОВ 1 июньдә 90 яшьлек юбилеен каршылый.**

**Сабыр холыклы, мәрхәмәтле, ярдәмчел, кадерледән-кадерле тормыш иптәшем, әтиебез, бабакаебыз!**

Шушындый зур һәм якты бәйрәмең көнендә без сиңа ихлас котлауларыбызны юллыйбыз. Син бит безнең өчен иң якын кешебез. Син булмасаң без оясыз кош, моңсыз җыр, җырсыз сандугач кебек яшәр идек, тормышыбызның яме дә, тәме дә булмас иде. Безнең өчен һәрчак олы җанлы, киң күңелле, булып калуың өчен мең рәхмәт сиңа. Без синең белән горурланабыз. Син гомер буе безнең өчен тырыштың, безне кеше итү өчен китте бөтен көчең, шуңа да без сиңа рәхмәтлебез. Ходай сине бездән, безне синнән аермасын. Һәрвакыт ярдәмчел, аңлаучан, тырыш булганың өчен Аллаһының мең рәхмәте яусын сиңа. Без сине бик-бик яратабыз!

*Рәхмәт сиңа, әти, озак яшә,*
*Бәхет, шатлык белән гомер ит.*
*Чәчәкләргә кояш ничек кирәк бит*
*Син дә безгә шулай кирәк бит.*
*Ал син бездән тәбрик сүзен,*
*Шушы булсын олы бүләкләр.*
*Тыныч тормыш белән гел яшә,*
*Озын гомер – безнең теләкләр.*
*Котлы булсын синең юбилееңң,*
*Бирсен Ходай саулык корычтай.*
*Якыннарың, балаларың белән*
*Озак яшә нурлы кояштай.*
*Күпме генә бәхет теләсәк тә,*
*Бик аз булыр кебек сизелә.*
*Ярдәм кулы суздың кирәк чакта,*
*Шәфкатьле син һәрбер кешегә.*



**Җылы теләкләр белән тормыш иптәшең Рауза, улың Ислам, киленең Ракыя, оныкларың Илдус, Илгиз-Венера, Ирек, Илсур, оныкчаң Илнар.**

Югары Тершка – Свердловск.

**В р.п. Старая Кулатка по ул. Нижне-Северная продается дом. Газовое отопление, центральное водоснабжение. Документы готовы. Тел. 8-929-797-34-34, 8-927-833-19-99.**

**Продается тележка для перевозки пчел, переоборудована в 2016 году. Также имеются новые алюминиевые фляги. Телефоны для справок: 89278331715, 2 – 18 -91.**




**5 июня**
**в районном Доме Культуры с 9 до 16 часов состоится ВЫСТАВКА-ПРОДАЖА ТОВАРА по сниженным ценам**
**В ассортименте: обувь, ветровки, камуфляж, джинсы, спортивные костюмы, толстовки, футболки, халаты, сорочки, полотенца, плеты, пост. бельё, детская одежда и многое другое.**

## Июнь аена намаз уку вакытлары

| Көн | Иртәнге намаз: Сәхәр тәмам Таң беленә | Иртәнге намаз: Мәчетләрдә укыла | Кояш чыга | Зәваль тәмам | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы (авыз ачу) | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 02:31 | 03:01 | 04:31 | 12:47 | 13:15 | 18:23 | 21:03 | 22:33 |
| 2 | 02:30 | 03:00 | 04:30 | 12:47 | 13:15 | 18:23 | 21:05 | 22:35 |
| 3 | 02:29 | 02:59 | 04:29 | 12:47 | 13:15 | 18:24 | 21:06 | 22:36 |
| 4 | 02:29 | 02:59 | 04:29 | 12:47 | 13:15 | 18:24 | 21:07 | 22:37 |
| 5 | 02:28 | 02:58 | 04:28 | 12:48 | 13:15 | 18:25 | 21:08 | 22:38 |
| 6 | 02:27 | 02:57 | 04:27 | 12:48 | 13:15 | 18:26 | 21:09 | 22:39 |
| 7 | 02:27 | 02:57 | 04:27 | 12:48 | 13:15 | 18:26 | 21:10 | 22:40 |
| 8 | 02:26 | 02:56 | 04:26 | 12:48 | 13:15 | 18:27 | 21:10 | 22:40 |
| 9 | 02:26 | 02:56 | 04:26 | 12:48 | 13:15 | 18:27 | 21:11 | 22:41 |
| 10 | 02:25 | 02:55 | 04:25 | 12:48 | 13:15 | 18:28 | 21:12 | 22:42 |
| 11 | 02:25 | 02:55 | 04:25 | 12:49 | 13:15 | 18:28 | 21:13 | 22:43 |
| 12 | 02:25 | 02:55 | 04:25 | 12:49 | 13:15 | 18:29 | 21:13 | 22:43 |
| 13 | 02:24 | 02:54 | 04:24 | 12:49 | 13:15 | 18:29 | 21:14 | 22:44 |
| 14 | 02:24 | 02:54 | 04:24 | 12:49 | 13:15 | 18:30 | 21:15 | 22:45 |
| 15 | 02:24 | 02:54 | 04:24 | 12:50 | 13:15 | 18:30 | 21:15 | 22:45 |
| 16 | 02:24 | 02:54 | 04:24 | 12:50 | 13:15 | 18:30 | 21:16 | 22:46 |
| 17 | 02:24 | 02:54 | 04:24 | 12:50 | 13:15 | 18:31 | 21:16 | 22:46 |
| 18 | 02:24 | 02:54 | 04:24 | 12:50 | 13:15 | 18:31 | 21:16 | 22:46 |
| 19 | 02:24 | 02:54 | 04:24 | 12:50 | 13:15 | 18:31 | 21:17 | 22:47 |
| 20 | 02:24 | 02:54 | 04:24 | 12:51 | 13:15 | 18:31 | 21:17 | 22:47 |
| 21 | 02:24 | 02:54 | 04:24 | 12:51 | 13:15 | 18:32 | 21:17 | 22:47 |
| 22 | 02:25 | 02:55 | 04:25 | 12:51 | 13:15 | 18:32 | 21:17 | 22:47 |
| 23 | 02:25 | 02:55 | 04:25 | 12:51 | 13:15 | 18:32 | 21:18 | 22:48 |
| 24 | 02:25 | 02:55 | 04:25 | 12:51 | 13:15 | 18:32 | 21:18 | 22:48 |
| 25 | 02:26 | 02:56 | 04:26 | 12:52 | 13:15 | 18:32 | 21:18 | 22:48 |
| 26 | 02:26 | 02:56 | 04:26 | 12:52 | 13:15 | 18:32 | 21:18 | 22:48 |
| 27 | 02:27 | 02:57 | 04:27 | 12:52 | 13:15 | 18:32 | 21:17 | 22:47 |
| 28 | 02:27 | 02:57 | 04:27 | 12:52 | 13:15 | 18:32 | 21:17 | 22:47 |
| 29 | 02:28 | 02:58 | 04:28 | 12:53 | 13:15 | 18:32 | 21:17 | 22:47 |
| 30 | 02:28 | 02:58 | 04:28 | 12:53 | 13:15 | 18:32 | 21:17 | 22:47 |

**Белешмәләр өчен телефон: 8-937- 451-24- 44.**

**Услуги эвакуатора.**
**Выкуп аварийных автомобилей.**
**☎Телефон: 89278229696.**

**Продается красный облицовочный кирпич, производство г.Тольятти. Гаражные ворота, утепленные. Справки по телефону: 8 – 927 – 815 – 3000.**

## ОБЪЯВЛЕНИЕ

1 июня 2017 г. с 9.00 до 18.00 ч. в муниципальном образовании «Старокулаткинский район» проводится День бесплатной юридической помощи с целью проведения консультаций для жителей района по правовым и гражданским вопросам. Прием граждан будет осуществляться по адресу: р.п. Старая Кулатка, ул. Пионерская, д. 30 (3 этаж здания администрации района – кабинет 314). Телефоны для справок: 2-13-52, 2-16-60 (возможна предварительная запись).

**Администрация муниципального образования «Старокулаткинский район».**

**ПЛАСТИКОВЫЕ ОКНА**
**Производство и установка пластиковых окон.**
**При заказе пяти окон, шестое – бесплатно!**
**Замер, доставка – бесплатно.**
***Наше качество и доступные цены порадуют вас! Пенсионерам – дополнительная скидка! 20%***
**☎ Телефон: 8-937-278-05-55.**
**Павловка.**



**Стоматология ООО «Дента Люкс»**



**приглашает вас воспользоваться качественными услугами современной стоматологии**
**пациентам нуждающимися в протезировании готовы предложить:**
**- съемное протезирование:**
**протезы из акриловых пластмасс, бюгельные, нейлоновые;**
**- несъемное протезирование: коронки с покрытием, металлокерамические, комбинированные, цельнолитые и.т.д.**
**Запись предварительно по тел.: 89278033404, Пионерская, 18 А. Консультация бесплатно.**

Безнең өчен иң якын кешебез, яраткан әнием, сеңелебез **Сания Иззәт кызы ГАТАУЛЛИНА** каты авырудан соң вафат булды. Бу хәсрәтне кичерү баласы Рафаэльга, абыйсына һәм апа – сеңелләренә бик авыр булды. Авыл халкы, туганнарыбыз, күршеләребез безне кайгыбыз белән ялгызыбызны калдырмадылар. Беренчеләрдән булып күршеләребез Флюра Марадуллина, Рамил Агрусев, Ринат Алиев һәм башкалар килделәр. Якын кешебезне соңгы юлга озатуда катнашкан, ярдәмләшкән, сәдака китерүчеләргә, кәфен кисеп, мәетне юучыларга, авылыбыз абыстайларына, мәдрәсә укучыларына, төн кунучы әбиләргә, сыйныфташлары Роза, Рифат, Наилә, Наҗия, Тәүхидә Ильясовага, Наилә, Фәнил Мохаммедовларга рәхмәтләребез зурдан. Яңгыр астында кабер казучы ир – атларга, җеназа догасын укучы авылыбыз имамнары Рушан Куртяковка, Әкрам Салиховка, Рушан Садретдиновка, Яңа Кулаткы, Иске Кулаткы, Радищеводан килгән якыннарыбызга, район больницасы табиблары Фәргать Гаязович Абитовка, Әлфия Рафаэльевна Масовага, шәфкать туташы Гөлнарага, Яңа Кулаткы авылы фельдшеры Суфиягә, үз авылыбызның шәфкать туташларына олы ихтирамыбызны һәм рәхмәт сүзләребезне юллыйбыз. Онытып калдырган кешеләргә, дога мәҗлесләрен үткәрүдә ярдәм итүчеләргә Аллаһы Тәгалә көч-куәт бирсен, әҗәр сәвапларын ирештерсен иде.

Бик зур рәхмәтләр белән **Гатауллин, Насыров, Курмашева, Салиховлар, Зориннар, Ибрагимовлар, Юсуповлар, Айсиннар.**

Иске Мостяк авылы.

**Директор-баш редактор М.С. МАСИЕВА.**

Адрес редакции, издателя: 433940 р.п. Старая Кулатка Ульяновской области, ул. Куйбышева, 22. ОАУ Редакция газеты "Кумяк кюч".

**Телефоннар:**
электрон адрес:
**kumiakk@mail.ru**
**884(249)2-11-94-редактор, факс, бухгалтерия;**
**884(249)2-12-64 - журналистлар, реклама бүлеге, РИК операторлары.**

**Индекс 54505.**
**Газетаны басарга кул кую вакыты: график буенча - 16.00 фактта - 16.00**
**Тираж 2825**
**Заказ № 13/22**
**Распространяется по подписке.**

**Газета отпечатана с готового оригинала-макета в ООО «Принт Хаус» 432071, г. Ульяновск, ул. Федерации, 15.**

**Элемтә һәм масса - күләм коммуникацияләр сферасында күзәтү буенча Федераль служабның Ульяновск өлкә идарәсе 2014 елның 21 ноябрендә ПИ №ТУ73-00388 номерлы масса-күләм информация чарасын регистрацияләү таныклыгы белән регистрацияләнде.**

**Газета битләрендә урнаштырылган рекламалар һәм белдерүләр өчен редакция җаваплылык тотмый.**

**Мәкаләә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.**

**Хатлар, кульязмалар һәм рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.**